Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2019нчы елның 17.06. чыккан 170 номерлы карары белән кабул ителде Кайбыч муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы рәисе

_______________А.И. Рәхмәтуллин

# «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ УСТАВЫ

(яңа редакциядә)

**Олы Кайбыч авылы**
**2019 нчы ел**

**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»**
**УСТАВЫ**

## I БҮЛЕК. ГОМУМИ КАГЫЙДАНӘМӘЛӘР

1 статья. Муниципаль Район һәм аның статусы

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасының 2005 елның 31 гыйварындагы 25-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» территориясе чикләрен һәм статусын билгеләү һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләр» Законы белән муниципаль район статусы бирелде.

2. Муниципаль берәмлекнең рәсми атамасы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» (текстта алга таба - Район), кыскача атамасы - «Кайбыч муниципаль районы».

2 статья. Районның территориаль төзелеше.

1. Район территориясе составына түбәндәге муниципаль берәмлекләр керә: Багай, Олы Кайбыч, Олы Подберезье, Олы Русак, Борындык, КоланГы, Кошман, Кече Мәми, Мәлки, Мөрәле, Надеждино, Иске Тәрбит, Ульянково, Федоровский, Хуҗа Хәсән, Чүти, Ябалак авыл җирлекләре.

2. Олы Кайбыч авылы районның административ үзәге булып тора.

3. Район чикләре Татарстан Республикасының 2005 елның 31 гыйнварындагы 25-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясе чикләрен һәм статусын билгеләү» һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләр» Законы белән билгеләнде.

4. Район чикләре Районның җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияткә ия булган җирлекара сорауларны чишү шартлары булдыру, шулай ук Районның бар территориясендә дә әйтелгән органнарга федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары тарафыннан бирелгән аерым дәүләт вәкәләтләрен гамәлгә ашыру максатында билгеләнде.

5. Район чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору Татарстан Республикасы законы тарафыннан кануннар төзүдә каралган тәртиптә, Районда яшәүчеләр фикерен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

3 статья. Районның рәсми символлары

1. Район үзенең рәсми символларына – тарихи, мәдәни һәм башка җирле традицияләр һәм үзенчәлекләрне чагылдыручы флаг, герб һәм гимнга ия.

2. Рәсми символларның тасвирламасы, аларны куллану тәртибе муниципаль берәмлек Советы тарафыннан расланучы Районның флаг, герб һәм гимны турындагы Нигезләмәләр белән билгеләнә.

3. Районның рәсми символлары федераль канунчылык тарафыннан каралган тәртиптә дәүләт теркәлүе үтәргә тиеш.

4 статья. Районда яшәүчеләрнең Районда җирле үзидарәгә хокукы

1. Районда җирле үзидарә Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан референдумнарда, муниципаль сайлауларда катнашу, ихтыярын бүтән рәвешле белдерү, шулай ук бу Уставта каралган җирле үзидарәнең сайлау һәм башка органнары аша гамәлгә ашырыла.

2. Гражданнар җирле үзидарәне гамәлгә ашыруга үзләре яки кем аша-дыр җенесе, милләте, теле, расасы, килеп чыгышына , мөлкәти һәм вазыйфаи хәленә , дингә мөнәсәбәтенә, карашларына, җәмгыятьтәге ниндидер берләшмәләргә керүенә карамастан тигез хокуклы.

Даими яисә күбесенчә Район территориясендә яшәүче чит ил гражданнары, Россия Федерациясенең халыкара килешүләре һәм федераль законнар нигезендә җирле үзидарәне гамәлгә ашыру хокукларына ия .

3. Районның һәр яшәүчесе җирле үзидарә органнарына, җирле үзидарәдәге вазыйфаи затларга турыдан-туры мөрәҗәгать итү, җирле үзидарә органнары турында мәгълүмат алу хокукына ия.

4. Районның җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары һәркемгә турыдан-туры аның хокуклары һәм ирегенә кагылучы документлар һәм материаллар, шулай ук, әгәр дә закон белән башкасы каралмаган булса, Районның җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат белән танышу мөмкинлеге тудырырга тиеш.

5. Районның җирле үзидарә органнары җирле халыкны даими рәвештә массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка юллар белән Районның һәм аның аерым территорияләренең аеруча мөһим мәсьәләләре, шулай ук гомуми кулланылучы транспорт, торак-коммуналь хуҗалык, халыкка хезмәт күрсәтүче социаль-мәдәни челтәр, башка оешма һәм хезмәтләр, социаль ташламалар, җәмәгать тәртибе саклау, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр белән 2009 елның 9 февралендәге «Дәүләт үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнары турында мәгълүмат белән танышып бару мөмкинлеге белән тәэмин итү турында» Федераль законы нигезендә таныштырып баралар.

6. Гражданнар, оешмалар җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларның гамәлләре (гамәлләрен үтәмәүләре) аша

хокуклары һәм ирекләре бозылган дип санасалар, суд аркылы килешмәүләрен белдерергә хокуклы.

5 статья. Районның җирле үзидарә органнары структурасы

1. Районның җирле үзидарә органнары структурасына бу Устав нигезендә оештырылучы Район Советы, Район Башлыгы, Районның Башкарма Комитеты, Районның Контроль хисап палатасы, Районның Финанс бюджет палатасы, Районның Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы, башка җирле үзидарә органнары керә.

2. Районның җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртү әлеге Уставка үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.

6 статья. Районның җирле әһәмияткә ия мәсьәләләре

1. Районның җирле әһәмияткә ия мәсьәләләренә түбәндәгеләр керә:

1) Район бюджет проектын төзү һәм карау, Район бюджетын раслау һәм үтәү, аны үтәүне контрольдә тоту, Район бюджетын үтәү турында хисап төзү һәм раслау;

2) Районның җирле салымнарын һәм җыюларны билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару;

3) Районның муниципаль милегендә булган милек белән файдалану һәм куллану;

4) Россия Федерациясе кануннары вәкаләтләре чикләрендә законнарда билгеләнгәнчә халыкны Район чикләрендә электр һәм газ белән тәэмин итүне оештыру;

5) Россия Федерациясе законнарына ярашлы итеп, Район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек, Район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияткә ия булган юлларның сакланышы, юл хәрәкәтен оештыру, юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү, шулай ук автомобиль юллары өлкәсендә башка вәкәләтләрне һәм юл эшчәнлеген тормышка ашыру;

6) Район чикләрендәге торак пунктлар арасында транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру ;

7) террорчылыкны профилактикалауда катнашу, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яисә) юкка чыгаруда катнашу мәсьәләләрен хәл иткәндә:

террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яисә) юкка чыгару өлкәсендә муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

муниципаль берәмлекләрдә террорчылыкның асылын һәм аның иҗтимагый куркынычын аңлату буенча мәгълүмати-пропаганда чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, шулай ук гражданнарда террорчылык идеологиясен кабул итмәү, шул исәптән мәгълүмати материаллар, басма продукция тарату, аңлату эшләре һәм башка чаралар үткәрү;

террорчылыкны профилактикалау чараларында катнашу, шулай ук федераль башкарма хакимият органнары һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органнары тарафыннан оештырыла торган аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яисә) ликвидацияләү;

муниципаль милектәге яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы объектларның террорчылыктан сакланышына карата таләпләрне үтәүне тәэмин итү;

террорчылыкны профилактикалауда катнашу, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) юкка чыгару мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органнарына тәкъдимнәр җибәрү;

террорчылыкны профилактикалауда катнашу буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яисә) юкка чыгаруда катнашу буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

8) милләтара һәм конфессия ара татулыкны ныгытуга юнәлдерелгән чараларны эшләү һәм тормышка ашыру, Район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен үстерү һәм ныгыту, милли азчылык хокукларын тәэмин итүне гамәлгә ашыру, мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләү, милләтара (халыкара) низагларны булдырмау максатында профилактикалау;

9) Район территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм нәтиҗәләрен бетерү;

10) Район территориясендә муниципаль милиция белән җәмәгать тәртибе саклауны оештыру;

11) Районның хезмәт күрсәтелүче административ участогы полиция участок уполномоченные вазыйфасын башкаручы хезмәткәргә эш урыны өчен бүлмә бирү;

12) 2017 елның 1 гыйнварына кадәр Районның хезмәт күрсәтелүче административ участогы полиция участок уполномоченные вазыйфасын башкаручы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына бу вазыйфасы буенча хезмәт күрсәткән чорга торак урын бирү;

13) әйләнә-тирә мохитне саклау буенча җирлекара характердагы чаралар үткәрү;

14) муниципаль гомумбелем ошмаларында төп гомуми белем программалары буенча һәркемгә кулай һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне (федераль дәүләт белем стандартларын гамәлгә ашырудан тыш финанслаудан кала), муниципаль гомумбелем ошмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру (балаларга өстәмә белем бирүне финанслау дәүләт власте органнары (Татарстан Республикасы) тарафыннан оештырыла торган өстәмә белем бирүдән кала), балаларны карауны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру, муниципаль гомумбелем ошмаларында балаларны тоту, шулай ук каникуллар вакытында үз вәкәләтләре чикләрендә балаларның тормышын һәм саулыгын түэмин итү чараларын кертеп ялын оештыру;

15) Район территориясендә яшәүчеләргә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләре территориаль программасы нигезендә, медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыру (Россия Федерациясе Хакимияте

тарафыннан расланган аерым территорияләрдә яшәүчеләргә башкарма властьның федераль органнарына хезмәт күрсәтүче медик-санитар хезмәте тарафыннан медицина ярдәме күрсәтелә торган территорияләр исемлегенә кергәннәрдән кала);

16) Район территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шулай ук аерым җыю), күчерү, эшкәртү, юкка чыгару, зарарсызландыру, күмү эшләрен оештыруда катнашу (2019 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә);

17) муниципаль район территорияләрен планлаштыру схемаларын раслау, муниципаль район территорияләрен планлаштыру схемалары нигезендә әзерләнгән документларны раслау, муниципаль район территориясендә шәһәртөзү эшчәнлеге турында мәгълүмати тәэмин итүне системага кертү, муниципаль район территориясе чикләрендәге җир кишәрлекләрен муниципаль ихтыяҗлар өчен резервка калдыру һәм алу, хәбәрнамә нигезендә күрсәтелгән планлаштырылган индивидуаль торак яки бакча йорты төзү планлаштыруны бу кишәрлеккә куелган параметрлар нигезендә башкару, хәбәрнамә нигезендә һәм бу җиргә индивидуаль торак яки бакча йорты төзү ярамауны белдерү, муниципаль район территориясендә төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак яки бакча йорты шәһәртөзү эшчәнлеге турында шартларга туры килү-килмәве турында хәбәрнамә бирү, Россия Федерациясе гражданлык кануничылыгы нигезендә авылара территориләрдә рөхсәтсез төзелгән корылмаларны юкка чыгару, авылара территориләрдә рөхсәтсез төзелгән корылмаларны юкка чыгару яки куелган таләпләргә яраклаштыру турында карарлар чыгару, авылара территориләрдә Россия Федерациясе канунчылыгына каршы килеп кулланылучы яки максатчан кулланылмаучы җир кишәрлекләрен алу турында карарлар чыгару, авылара территориләрдә рөхсәтсез төзелгән корылмаларны юкка чыгару яки куелган таләпләргә яраклаштыруны Россия Федерациясе Шәһәр төзү кодексы нигезендә гамәлгә ашыру;

18) Район территориясендә реклама конструкцияләре кую, аларны куюга рөхсәт бирү, мондый рөхсәт бирүләрне юкка чыгару, рөхсәтсез урнаштырылган реклама конструкцияләрен алдыру турында күрсәтмәләр бирүне 2006 елның 13 мартындагы «Реклама турында» Федераль законы нигезендә гамәлгә ашыру;

19) җирлек архив фондларын да кертеп, муниципаль архив оештыру һәм тоту;

20) Район территориясендә авылара күмү урыннары тоту, ритуаль хезмәтләр күрсәтү;

21) Район составына керүче җирлекләрдә элемтә, гомуми туклану, көнкүреш хезмәте күрсәтүгә шартлары тудыру;

22) халыкка авылара китапханә хезмәте күрсәтүне, китапханә фондларын комплектлау һәм саклау эшен оештыру;

23) Район составына керүче җирлекләрдә мәдәният оешмалары хезмәте күрсәтү һәм ялны оештыру;

24) Район составына керүче җирлекләрдә урындагы традицион иҗат өчен шартлар булдыру;

25) Район территориясендә урнашкан, Район милкенә караган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау, куллану һәм популярлаштыру;

26) Район составына керүче җирлекләрнең бюджет белән тәэмин ителешен Район бюджеты хисабына тигезләштерү;

27) Район территориясендә халыкны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы буенча чаралар оештыру һәм гамәлгә кую;

28) Район территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклanучы табигый территорияләрне куллану һәм саклауны муниципаль контрольләүне гамәлгә ашыру;

29) Район территориясендә булган муниципаль оешма һәм предприятияләрнең мобилизацион әзерлеге буенча чаралар оештыру һәм гамәлгә кую;

30) су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын булдыру буенча чараларны гамәлгә кую;

31) җирлекләрдә авыл хуҗалыгы үсеше өчен шартлар тудыру, авыл хуҗалыгы продукциясе, азык-төлек һәм чимал базарын киңәйтү, кече һәм урта эшкуарлык үсешенә, социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмаларга, волонтерлыкка, иганәчелек эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү;

32) Район территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсешенә шартлар булдыру, Районның рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру;

33) балалар һәм яшьләр белән җирлекара чаралар үткәрүне оештыру һәм гамәлгә кую;

34) Россия Федерациясе су канунчылыгы һәм су объектлары милекчесе вәкаләтләре чикләрендә су объектларын гомуми кулланунын, гражданнарның су объектларын һәм аларның яр полосаларын ирекле куллануын кертеп, шәхси һәм көнкүреш кагыйдәләрен билгеләү;

35) муниципаль урман контроле белән тәэмин итү;

36) Район ихтыяҗы өчен ясалма җир участоклары булдыру эшләре тәэмин итү, федераль закон нигезендә ясалма җир участоклары ясау эшләре буенча шартнамә төзүгә ачык аукцион үткәрү;

37) Район чикләрендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру;

38) урам-юл челтәре объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль мәгънәгә ия автомобиль юллары, региональ һәм муниципальара автомобиль юлларыннан кала) атамалар бирү, мондый атамаларны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару, дәүләт адрес реестрында мәгълүмат урнаштыру;

39) Районның авылара территориясендә җир контролен гамәлгә кую;

40) 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы «Кадастр эшчәнлек турында» Федераль законы нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкару һәм территориянең карта-планын раслау.

2. Район авыл җирлекләре территорияләрендә авыл җирлекләре өчен җирле мәгънәгә ия булмаган, Район өчен җирле мәгънәгә ия сорауларына түбәндәгеләр карый:

1) Район составына керүче авыл җирлекләре чикләрендә Россия Федерациясе кануннары вәкаләтләре билгеләгәнчә халыкны электр һәм газ белән тәэмин итүне оештыру;

2) җылылык белән тәэмин итү бәя зоналарында җылылык белән тәэмин итү оешмасының төзелеш, җылылык белән тәэмин итү объектларын җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның нәтиҗәлелеген арттыру максатында реконструкцияләвен һәм (яисә) яңартуын 2010 елның 27 июлендәге «Җылылык белән тәэмин итү турында» Федераль законы биргән вәкәләтләр кысаларында муниципаль контрольдә тоту ;

3) Россия Федерациясе законнарына ярашлы итеп, торак пунктлар чикләрендә торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек (парковка урыннары булдыру һәм аларны эшләтүне тәэмин итүне дә кертеп), җирле әһәмияткә ия булган юлларның сакланышы, юл хәрәкәтен оештыру, юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү, шулай ук автомобиль юллары өлкәсендә башка вәкәләтләрне һәм юл эшчәнлеген тормышка ашыру;

4) авыл җирлекләрендә яшәүче азкеремле һәм торак белән тәэмин итүгә мохтаҗ гражданнарны торак урыннар белән тәэмин итү, муниципаль торак фонды төзүне булдыру һәм аны тоту, торак төзелеш өчен шартлар булдыру, муниципаль торак контролен гамәлгә кую, шулай ук җирле үзидарәнең торак канунчылык белән бәйле башка вәкәләтләрен тормышка ашыру;

5) авыл җирлекләрендә торак пунктлар арасында транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру;

6) авыл җирлекләре чикләрендә терроризм һәм экстремизм профилак-тикасында катнашу, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү;

7) авыл җирлекләре чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм нәтиҗәләрен бетерү;

8) авыл җирлекләрендә китапханә хезмәте күрсәтүне, китапханә фонд-ларын комплектлау һәм саклау эшен оештыру ;

9) авыл җирле милкенә караган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау, куллану һәм популярлаштыру ;

10) авыл җирлекләрендә урындагы традицион иҗат үсеше өчен шартлар булдыру; авыл җирлекләрендә халык сәнгать һөнәрләрен саклау, торгызу, үстерү эшендә катнашу;

11) җирлекнең генераль планын, җирдән куллану һәм төзү кагыйдәләрен раслау, территорияне планлаштыру буенча җирлекнең генераль планы нигезендә әзерләнгән документацияне раслау, төзелеш эшенә рөхсәт бирү (Россия Федерациясе Шәһәр төзү кодексында каралган очраклардан, башка законнардан кала), җирлек территорияләрендә урнашкан капиталь төзелешь объектларын эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, җирлек территориясен проектлауның урындагы нормативларын раслау, җирлек чикләрендәге җир кишәрлекләрен муниципаль ихтыяҗлар өчен резервка калдыру һәм алу, җирлек чикләрендә муниципаль җир контролен тормышка ашыру,хәбәрнамә нигезендә күрсәтелгән планлаштырылган индивидуаль торак яки бакча йорты төзү планлаштыруны бу кишәрлеккә куелган

параметрлар нигезендә башкару, Россия Федерациясе Шәһәртөзү кодексы нигезендә корылма,зданиеләрне карау, шундый караулар барышында ачыкланган канун бозуларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр бирү, хәбәрнамә нигезендә һәм бу җиргә индивидуаль торак яки бакча йорты төзү ярамауны белдерү, муниципаль җирлек территориясендә төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак яки бакча йорты шәһәртөзү эшчәнлеге турында шарт-ларга туры килү-килмәве турында хәбәрнамә бирү, Россия Федерациясе гражданлык канунчылыгы нигезендә авылара территориләрдә рөхсәтсез төзелгән корылмаларны юкка чыгару, авылара территориләрдә рөхсәтсез төзелгән корылмаларны юкка чыгару яки куелган таләпләргә яраклаштыру турында хәбәрнамәләр бирү, гамәлгә куелган җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, территорияне планлаштыру документациясен тикшерүне, җирлек терри-торияләрендә Россия Федерациясе канунчылыгына каршы килеп кулла-нылучы яки максатчан кулланылмаучы җир кишәрлекләрен алу турында хәбәрнамә бирү, авылара территориләрдә рөхсәтсез төзелгән корылмаларны юкка чыгару яки куелган таләпләргә яраклаштыруны Россия Федерациясе Шәһәр төзү кодексы нигезендә гамәлгә ашыру;

12) авыл җирлеге территорияләрен һәм халкын табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы буенча чаралар оештыру һәм гамәлгә кую;

13) авыл җирлеге территорияләрендә һәлакәт-коткару хезмәтләре һәм (яисә) һәлакәт-коткару формированиеләре булдыру, тоту һәм эшен оештыру;

14) авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан су объектларында кеше тормышы һәм саулыгы куркынычсызлыгы чараларын тормышка ашыру;

15) авыл җирлекләре территорияләрендә җирле әһәмияттәге дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклanучы табигый территорияләрне куллану һәм саклауны муниципаль контрольләүне гамәлгә ашыру;

16) Россия Федерациясе су канунчылыгы һәм су объектлары милекчесе вәкаләтләре чикләрендә халыкны су объектларын куллануның чикләүләре белән таныштыру;

17) муниципаль урман контроле белән тәэмин итү ;

18) хезмәт күрсәтелүче административ участок полиция участок уполномоченные вазыйфасын башкаручы хезмәткәргә эш урыны өчен бүлмә бирү;

19) полиция участок уполномоченные вазыйфасын башкаручы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына бу вазыйфасы буенча хезмәт күрсәткән чорга торак урын бирү;

20) коммерцияле булмаган социаль ориентлашкан оешмаларга «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» Федераль законының (12.01.1996) 31.1 һәм 31.3статьялары нигезендә ярдәм күрсәтү;

21) авыл җирлекләре ихтыяҗы өчен ясалма җир участоклары булдыру эшләре тәэмин итү, федераль закон нигезендә ясалма җир участоклары ясау эшләре буенча шартнамә төзүгә ачык аукцион үткәрү;

22) авыл җирлекләре чикләрендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру;

23) авыл җирлекләре чикләрендә 2007 елның 24 июнендәге 221-ФЗ номерлы «Кадастр эшчәнлек турында» Федераль законы нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкаруда катнашу.

3. Район җирле үзидарә органнары Район составына керүче башка җирле үзидарә органнары белән аларга үз вәкәләтләренең Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Район бюджетыннан әйтелгән җирлек бюджетларына бюджеташа трансфертлар хисабына җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне чишү буенча килешү төзүгә хокуклы.

7 статья. Районның җирле әһәмияткә ия мәсьәләләргә карамый торган сорауларны чишүгә хокукы

1. Район җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Район музейларын төзү;

2) опека һәм попечительлек буенча эшчәнлекне тормышка ашыруда катнашу;

3) Район территориясе белән бәйле җирле милли-мәдәни автономияләр хокукларын тормышка ашыру белән бәйле эшчәнлек башкаруга шартлар тудыру;

4) Район территориясендә Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларга ярдәм күрсәтү;

5) 2008 елның 31 декабренә алар карамагында булган югары белем муници-паль белем оешмаларын гамәлгә ашыру функцияләрен гамәлгә кую;

6) туризм үсеше өчен шартлар тудыру;

7) кеше хокукларын тәэмин итүне җәмәгать күзәтүендә тотучы җәмәгать күзәтү комиссияләренә һәм мәҗбүри тоту урыннарында булган затларга ярдәм күрсәтү;

8) 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе инвалидларын социаль яклау» Федераль инвалидларның җәмәгать оешмаларына ярдәм күрсәтү;

9) 2012 елның 20 июлендәге 125-ФЗ номерлы «Кан һәм анның компонентлары донорлыгы» Федераль законы белән каралган чараларны тормышка ашыру ;

10) авылара территория торак пунктында нотариус булмаган очракта, нотариаль эшчәнлек башкару;

11) федераль законнар нигезендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын федераль законнар нигезендә бәйсез бәяләү уздыруга шартлар тудыру, шулай ук оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен ведомство буйсынуындагы оешма җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә, оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын тикшергәндә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү өчен чаралар кабул итү буенча куллану;

12) хокук бозуларны кисәтү өлкәсендә 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә хокук бозуларны кисәтү системасы нигезләре турында» Федераль законында каралган чараларны тормышка ашыру;

13) инвалидлар һәм мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культура һәм спорт, адаптив физик культура һәм адаптив спорт белән шөгыльләнүенә ярдәм күрсәтү;

14) Россия Федерациясенең 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы «Кулланучылар хокукларын саклау турында» Законында каралган кулланучылар хокукларын саклау чараларын тормышка ашыру.

2. Районның җирле үзидарә органнары бу статьяның 1нче бүлегендә күрсәтелгән сорауларны чишәргә, башка дәүләт вәкәләтләрен (2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 19нчы статьясы нигезендә бирелмәгән) гамәлгә куюда катнашырга, әгәр бу катнашу федераль законнар белән каралган булса, шулай ук башка муниципаль җирлекләрнең, дәүләт власть органнарының җирле үзидарә органнары компетенциясенә кермәгән һәм алар компетенциясеннән федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән чыгарма ителмәгән бүтән мәсьәләләрен чишүдә урындагы бюджет керемнәре, (бюджет системасының Россия Федерациясе бюджетыннан бирелгән бюджетара трансфертлардан кала), һәм өстәмә нормативлар кертемнәре салым керемнәре исәбеннән катнашырга хокуклы.

8 статья. Районның җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкәләтләре бирү

Районның җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкәләтләре бирү федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән гамәлгә куела.

Районның җирле үзидарә органнары бирелгән дәүләт вәкәләтләре өчен, бу максатларга каралган материаль ресурслар һәм иктисадый чаралар чикләрендә ,федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән каралган тәртиптә җаваплы.

Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру дәүләт контролендә. Районның җирле үзидарә органнары тарафыннан аерым дәүләт вәкәләтләрен гамәлгә куюны контролҗләү шартлары һәм тәртибе федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә. Район Советы үз вәкәләтләре чикләрендә Районның җирле үзидарә органнары тарафыннан аерым дәүләт вәкәләтләрен гамәлгә куюда Районның җирле үзидарә органнары карамагында булган материаль ресурслар һәм иктисадый чараларның өстәмә очракларын һәм тәртибен билгеләргә хокуклы .

9 статья. Районның муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы

Районның муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы җирле үзидарә турында федераль һәм Татарстан Республикасы канунчылыгы нигезендә гамәлгә куела.

10 статья. Районның җирле үзидарә органнарының дәүләт власте органнары белән мөнәсәбәтләре

Районның җирле үзидарә органнарының дәүләт власте органнары белән мөнәсәбәтләре түбәндәгеләр аша гамәлгә ашырыла:

1) Районның җирле үзидарә органнарының Районның социаль-икътисадый үсешенә юнәлтелгән дәүләт программаларын тормышка ашыруда катнашуы;

2) Районның җирле үзидарә органнарының дәүләт власте органнары белән шартнамәләр (килешүләр) төзүе;

3) даими яки вакытлы координацион, консультатив, киңәшмә һәм башка эш органнары булдыру;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Район Советы законнчыгару инициативасы булдыру;

5) канунчылык белән каралган башка тәэсир итү формалары белән.

11 статья. Муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу

Районда муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу, муниципаль хезмәт вазыйфаларын кертеп, муниципаль хезмәткәр статусын, муниципаль хезмәт үтү шартлары һәм тәртибен билгеләп, 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт» Федераль законы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт Кодексы, Район Советы, Районның муниципаль хокукый актлары белән расланган муниципаль хезмәт турында Нигезләмәсе белән гамәлгә куела.

## II Бүлек. ҖИРЛЕ ХАЛЫКНЫҢ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ТУРЫДАН-ТУРЫ ГАМӘЛГӘ КУЮ ҺӘМ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ГАМӘЛГӘ КУЮДА КАТНАШУ ФОРМАЛАРЫ

12 статья. Җирле үзидарәне гамәлгә куюда халыкның турыдан-туры катнашуы

Район халкы турыдан-туры үзидарәне гамәлгә куюда түбәндәге формаларда катнаша:

1) урындагы референдум;

2) Районны һәм аның чикләрен турындагы мәсьәләләр буенча сайлаулар ;

3) гражданнарның хокук чыгару инициативасы;

4) ачык тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышу;

5) гражданнар җыелышлары;

6) гражданнар конференцияләре (делегатлар җыелышы);

7) гражданнарны сораштыру;

8) җирле мәгънәгә ия мәсьәләләрдә халык фикер алышуы;

9) гражданнарның җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгате;

10) Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка формалар.

13статья. Җирле референдум

1. Җирле референдум халык белән турыдан-туры җирле мәгънәгә ия мәсьәләләрне федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына таянып чишү максатларында үткәрелә.

2. Җирле референдум бөтен Район территориясендә 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу хокукы төп гарантияләре һәм сайлау хокуклары» Федераль законы һәм Татарстан Республикасының 2004 елның 24 мартындагы 23-ЗРТ номерлы «Җирле референдум турында» Законында (2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федеральным законы нигезендә каралган үзенчәлекләрне кертеп) каралган тәртиптә уздырыла.

3. Җирле референдумда яшәү урыны Район чикләрендә булган Россия Федерациясе гражданнары катнашырга хокуклы Район территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнары Россия Федерациясе халыкара шартнамәләре һәм закон нигезендә каралган тәртиптә җирле референдумда Россия Федерациясе гражданнары кебек үк катнаша ала.

Россия Федерациясе гражданнары җирле референдумда гомуми тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә яшерен тавыш биреп катнаша.

4. Җирле референдум билгеләү турында Район Советы карары:

1) Җирле референдумда катнашырга хокуклы гражданнар;

2) уставлары сайлауларда һәм (яки) референдумнарда катнашуны рөхсәт итә торган һәм федераль закон белән каралган тәртиптә һәм вакытта теркәлгән сайлау берләшмәсенең, башка иҗтимагый берләшмәнең;

3) Район Советы һәм Районның Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан , яисә аларның уртак инициативасы белән чыгарыла.

5. Җирле референдумны гражданнар, сайлау берләшмәсе, башка иҗтимагый берләшмәләрнең инициативасы билгеләвенә әлеге инициативага ярдәмгә Район территориясендә теркәлгән референдумда катнашучыларның биш проценты күләмендә, ләкин 25тән азрак булмаган санда имзалар җыю шарт.

6. Район Советы һәм Районның Башкарма комитет җитәкчесе уртак инициативасы белән референдум үткәрү Район Советы һәм Районның Башкарма комитеты карары белән рәсмиләштерелә. Әлеге инициативаны күрсәтү тәртибе Район Советы норматив хокукый акты белән билгеләнә.

7. Район Советы җирле референдумны Район Советына җирле референдум үткәрүгә нигез булып торган документлар кергәннән соң 30 көн эчендә билгели.

8. Референдумда сайлау үткәрү датасы Район Советы карары белән билгеләнгән сайлау көненнән алда, 25 көннән дә соңга калмыйча, дәүләт власте яки җирле үзидарә органнарына сайлаулар, яки икенче билгеләнгән реферундум көне белән берләштерү максатында соңрак срокка күчерелергә мөмкин (ләкин 90көннән дә соңракка түгел ).

9. Сайлау нәтиҗәләре һәм җирле референдумда чыгарылган карар Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм «Кайбыч таңнары» газетасында рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

10. Җирле референдумда чыгарылган карар Район территориясендә һичшиксез гамәлгә куелырга тиеш һәм ниндидер дәүләт власте яисә Районның җирле үзидарә органнары, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан раслауга мохтаҗ түгел.

11. Районның җирле үзидарә органнары җирле референдумда чыгарылган карарның үтәлешен әлеге Устав белән каралган алар арасында вәкәләтләрне бүлү нигезендә тәэмин.

12. Җирле референдум билгеләү турында , шулай ук референдумда кабул ителгән карар гражданнар, җирле үзидарә органнары, Кайбыч муниципаль Районы прокуроры, федераль закон нигезендә вәкалэтле дәүләт хакимияте органнары тарафыннан суд тәртибендә кире кагылырга мөмкин.

14 статья. Районны, Район чикләрен үзгәртү мәсьәләләре буенча тавыш бирү

1. Районны, Район чикләрен үзгәртү мәсьәләләре буенча тавыш бирү Районны, чикләрен үзгәртү мәсьәләләре буенча халыктан ризалык алу максатында үткәрелә.

2. Районны, Район чикләрен үзгәртү мәсьәләләре буенча тавыш бирү Районның бөтен территориясендә яки 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы нигезендә каралган очракларда, аның бер өлешендә уздырыла.

3. Районны, Район чикләрен үзгәртү мәсьәләләре буенча тавыш бирү Район Советы белән билгеләнә һәм 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу хокукы төп гарантияләре һәм сайлау хокуклары» Федераль законы һәм Татарстан Республикасының 2004 елның 24 мартындагы 23-ЗРТ номерлы «Җирле референдум турында» Законында каралган (2003нче елның 6нчы октябрендә чыккан 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы нигезендә каралган үзенчәлекләрне кертеп) тәртиптә уздырыла.

4. Районны, Район чикләрен үзгәртү мәсьәләләре буенча тавыш бирү анда Районда яки Районның бер өлешендә сайлау хокукына ия яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашкан булса үткән булып санала. Элеге үзгәртү өчен Районда яки Районның бер өлешендә тавыш бирүчеләрнең яртысыннан артыгы

тавыш биргән булса, Районны, Район чикләрен үзгәртү буенча халыкның ризалыгы алынган дип санала.

5. Районны, Район чикләрен үзгәртү мәсьәләләре буенча тавыш бирү нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм «Кайбыч таңнары» газетасында рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

15 статья. Гражданнарның хокукый инициативасы

1. Район халкы әлеге Устав һәм Район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә хокукый инициатива белән чыгарга хокуклы.

2. Хокукый инициатива белән сайлау хокукына ия булган Район санынннан 3 проценттан да артмаган санда халык чыгарга мөмкин.

3. Хокукый инициативаны тормышка ашыру максатыннан Районда яшәүчеләр түбәндәге хокуклы ия:

- яшәү (эш) урыны буенча гражданнар җыелышлары һәм хокук чыгару инициативасы турында фикер алышу һәм чыгару турында башка күмәк чаралар оештырырга һем үткәрергә;

- хокук чыгару инициативасы хәрәкәтенә ярдәм итүгә имза җыю буенча инициатив төркемнәр төзергә;

- Район халкының имзаларын җыю һәм канунчылыкка каршы килмәгән юллар белән хокук чыгару инициативасы хәрәкәтенә теләктәшлек йөзеннән агитация алып барырга.

4. Район җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары хокук төзү инициативасын гамәлгә ашыруда җирлек халкына ярдәм күрсәтергә тиеш.

5. Гражданнарның хокук чыгару инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль хокукый акт проекты, Район Советы тарафыннан аның ачык утырышында, әлеге Устав белән билгеләнгән компетенция нигезендә, Район Башлыгы яисә Башкарма Комитет җитәкчесе тарафыннан аны кертү көненнән өч ай дәвамында мәҗбүри карап тикшерелергә тиеш.

6. Гражданнарның хокук чыгару инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль хокукый акт проектын караганда гражданнарның инициатив төркеме вәкилләренә үз позицияләрен бәян итү мөмкинлеге тудырылырга тиеш.

7. Гражданнарның хокук чыгару инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль хокукый акт проектын карау процедурасы Район Советы Регламенты, Район Башлыгы, Район Башкарма комитеты норматив хокукый акты белән билгеләнә.

8. Гражданнарның хокукый инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль хокукый акт проектын карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән дәлилләнгән карар рәсми рәвештә аны керткән гражданнарның инициатив төркеме игътибарына җиткерелергә тиеш.

16 статья. Халык тыңлаулары, иҗтимагый фикер алышулар

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар проектлары турында фикер алышу Район халкы, Район Советы, Район Башлыгы катнашында халык тыңлаулары үткәрелергә мөмкин.

2. Халык тыңлаулары халык, Район Советы, Район Башлыгы, Район Башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча үткәрелә. Халык тыңлаулары, Район Советы инициативасы белән узучы халык тыңлаулары Район Советы, ә Район Башлыгы яки Район Башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән үткәрелсә, Район Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

3. Халык тыңлауларына түбәндәгеләр чыгарга тиеш:

1) Район Уставы проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты, Уставка үзгәрешләр (җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм аларны хәл итү вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә яки Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында гына кертелә торган очраклардан тыш);

2) Район бюджеты проекты һѐм аның үтәлеше турында хисап;

3) муниципаль җирлекнең социаль-икътисадый стратегик үсеше проекты;

4) 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 13статьясында каралган муниципаль җирлекне үзгәртү өчен халыкның ризалыгын тавыш бирү яки гражданнар җыенында алу кирәк булган очраклардан тыш, Районны үзгәртү турында мәсьәләләр;

5. Халык тыңлаулары үткәрү турында карар һәм анда каралачак муниципаль хокукый акт проекты үткәрү урынын һәм төгәл вакытын күрсәтеп, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм «Кайбыч таңнары» газетасында рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

6.Халык тыңлауларын үткәрү турындагы карар басылып чыккан көненнән башлап һәм аларны үткәрелгән көнгә кадәр Район халкы ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм кисәтүләрне, шул исәптән проектка карата муниципаль хокукый актның гавами тыңлауларына бирелә торган төзәтмәләр һәм башка тәкъдимнәрен Район Башлыгына җибәрә ала. Район Башлыгы кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерүне оештыра. Күрсәтелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр халык тыңлауларында катнашучылар игътибарына җиткерелә.

7.Халык тыңлаулары, гамәлдәге канунчылыкта башкасы каралмаган булса, муниципаль хокукый акт проектын карау көненә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча уздырыла. Халык тыңлаулары а кызыксынучы затларны, белгечләр, экспертларны чакырып үткәрелә. Халык тыңлауларында Районның теләсә кайсы кешесе катнаша ала.

8.Халык тыңлауларын үткәрү йомгаклары буенча муниципаль хокукый акт проектын җирле үзидарә органнары һәм Районның вазыйфаи затлары тарафыннан мәҗбүри карап тикшерелергә тиешле халык алдында тыңлауларга чыгару хәл ителгән тәкъдимнәр кабул ителә.

9. Халык тыңлауларының нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезен кертеп, гавами тыңлаулар үткәргәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм «Кайбыч таңнары» газетасында рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка игълан ителгән) тиеш.

10. Халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе Район Советы тарафыннан расланган гавами тыңлаулар турындагы Нигезләмә белән билгеләнә.

11. Генераль планнар, җирне куллану һәм төзелеш проектлары территорияне планлаштыру проектлары, территорияне мижалау проектлары, территорияне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларга үзгәрешләр кертү проектлары, җир кишәрлеген шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төре яисә капиталь төзелеш объекты турындагы рөхсәт карары проекты, рөхсәт ителгән төзелеш параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында карар проектлары, капиталь төзелеш объектлары реконструкциясе проектлары, җирне куллану һәм, капиталь төзелеш объектларын расланган җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаганда, шундый икенче төрле куллануга үзгәртү сораулары буенча халык тыңлаулары һәм иҗтимагый фикер алышулар үткәрелә. Аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе муниципаль җирлек һәм (яисә) муниципаль җирлекнең вәкиллек органы шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон нигезләмәләрен исәпкә алып төзелгән норматив хокукый акты нигезендә билгеләнә.

17 статья. Территориаль иҗтимагый үзидарә

1. Районда территориаль иҗтимагый үзидарә турыдан туры халык тарафыннан гражданнар җыелышлары һәм конференцияләре үткәреп, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә органнары төзеп гамәлгә ашырыла.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарә гражданнар яши торган түбәндәге территорияләр чикләрендә гамәлгә ашырыла: күпфатирлы йорт подъезды; күпфатирлы йорт; торак йортлар төркеме; торак микрорайон; җирлек булмаган авыл торак пункты; гражданнар яши торган башка территорияләр.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территория чикләре бу территориядә яшәүче халык тәкъдиме буенча әлеге җирлекнең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.

4. Территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территория икенче аналогик территория составына керә алмый.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарә үзенең уставы нигезендә юридик зат була ала һәм оештыру -хокукый формасы буенча коммерцияле булмаган оешма буларак дәүләт теркәве үтәргә тиеш.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставында түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) ул гамәлгә ашырыла торган территория;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә максатлары, бурычлары, эшчәнлегенең формалары һәм төп юнәлешләре;

3) вәкаләтләрен барлыкка китерү, юкка чыгару тәртибе, территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының хокуклары һәм вазыйфалары, вәкаләтләренең срогы;

4) карар чыгару тәртибе;

5) милек сатып алу тәртибе, шулай ук күрсәтелгән милекне куллану һәм финанс чараларын тоту тәртибе;

6) территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә куюны туктату тәртибе.

7. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге мәсьәләләре буенчак җыелышлыр, конференцияләр аның уставы нигезендә үткәрелә.

8. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә кую мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышлары әлеге территориядә яшәүче уналты яшькә җиткән халыкның өчтән бере катнашса хокукый дип санала.

Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар конференциясе, әгәр анда территориядә яшәүче уналты яшькә җиткән гражданнарның кимендә өчтән берен тәшкил итүче һәм җыелышларда сайланган делегат гражданнарның кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

9. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыручы гражданнар җыелышының, конференциясенең махсус вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары структурасын билгеләү;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын сайлау;

4) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү;

5) территориаль иҗтимагый үзидарә керемнәре һәм чыгымнары сметасын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары эшчәнлеге турында хисапларны карау һәм раслау.

10. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары:

1) тиешле территориядә яшәүче халык мәнфәгатьләрен күрсәтә;

2) гражданнар җыелышларында һәм конференцияләрендә кабул ителгән карарларның үтәлешен тәэмин итә;

3) территорияне төзекләндерү буенча хуҗалык эшчәнлеген, тиешле территориядә яшәүче гражданнарның социаль-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән башка хуҗалык эшчәнлеген күрсәтелгән гражданнар акчалары исәбеннән дә, җирле бюджет чараларын кулланып җирле үзидарә органнары белән шартнамә нигезендә дә гамәлгә ашыра алалар;

4) күрсәтелгән актларны кабул итү үз компетенцияләренә кертелгән әлеге органнар һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан мәҗбүри каралырга

тиешле муниципаль хокукый актлар проектларын Район Советына, Район башлыгына һәм Районның башкарма комитетына кертергә хокуклы.

11. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе җирлек уставы һәм җирлек вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

Җирле бюджеттан кирәкле акчаларны бүлеп бирү шартлары һәм тәртибе тиешенчә җирлек уставы һәм (яисә) җирлек вәкиллекле органының норматив хокукый актлары, Район Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

18 статья. Халык җыелышы

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча фикер алышу, халыкка җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм Районның җирле үзидарә вазыйфаи затлары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү, өчен гражданнар җыелышы үткәрелә ала. Гражданнарның җыелышлары микрорайоннар, торак массивлар, кварталлар, урамнар, торак йортлар буенча чакырыла.

2. Гражданнар җыелышы халык, Район Советы, Район Башлыгы инициативасы белән, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә уставында каралган очраклар инициативасы белән үткәрелә.

3.Район Советы яки Район Башлыгы инициативасы белән үткәрелгән гражданнар җыелышы Район Советы яки Район Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

4. Халык инициативасы буенча уздырылучы гражданнар җыелышы, әлеге территориядә яшәүче кешеләр санының 10 процентыннан да ким булмаган , һәм әлеге территорияләрдә урнашкан предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләре катнашында, җыелышта катнашырга хокукы булган гражданнар төркеме язма тәкъдиме буенча Район Советы тарафыннан билгеләнә.

Гражданнар җыелышын үткәрү турындагы тәкъдимдә анда карау өчен чыгарылган мәсьәләләр исемлеге, тәкъдим ителә торган җыелышны үткәрү урыны һәм вакыт булырга тиеш. Тәкъдим вәкаләтле затлар тарафыннан имзаланырга тиеш, ә җыелыш уздыру инициативасы белән гражданнар төркеме чыкса, бу гражданнарның фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, туган датасын, яшәү адресын күрсәтеп , алар тарафыннан имзаланырга тиеш.

Район Советы гражданнар җыелышын үткәрү турындагы тәкъдимне үзенең якындагы утырышында карый.

Район Советы максатка ярашлы түгел дип, гражданнар җыелышы үткәрүдән баш тартырга хокуклы түгел.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе территориаль иҗтимагый үзидарә Уставы белән билгеләнә.

6. Гражданнар җыелышын үткәрү вакыты һәм урыны турында фикер алышуга кертелә торган мәсьәләләр турында тиешле территориядә яшәүчеләргә җыелышны үткәрү көненә кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә, моның өчен массакүләм мәгълүмат чараларыннан файдаланып, почта хәбәрнамәләре, һәр

фатирны аерым (утар) обходлар, игъланнар һәм башка мөмкин чаралар белән хәбәр ителә. Җыелышны әзерләү һәм үткәрү белән Район Башкарма Комитеты тәэмин итә.

7. Җыелышлар эшендә әлеге территориядә яшәүче, сайлау хокукына ия булган гражданнар катнашырга хокуклы. Җыелышта катнашу хокукына ия гражданнарның гомуми саны Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе чикләрендә булу һәм яшәү урыны буенча, муниципаль сайлауларны үткәрүдә файдаланыла торган теркәү исәбен алу мәгълүматлары нигезендә билгеләнә.

Җыелышта катнашырга хокукы булган гражданнар санының өчтән бер өлеше җыелышта булса, гражданнар җыелышы үткәрү хокукый дип санала.

Җыелышның карарлары җыелышта катнашкан гражданнарның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

8. Гражданнар җыелышы Районның җирле үзидарә органнарына һәм вазыйфаи затларына карата мөрәҗәгатьләр кабул итә, шулай ук Районның җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары белән үзара мөнәсәбәтләрдә гражданнар җыелышын тәкъдим итүче вәкилләр сайларга мөмкин.

9.Территориаль җәмәгать үзидарәсен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча үткәрелә торган гражданнар җыелышы аның компетенциясенә территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән кертелгән мәсьәләләр буенча карар кабул итә.

10.Гражданнар җыелышы тарафыннан кабул ителгән мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгатьләрдә булган мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренә кертелгән Район җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан язмача җавап җибиреп, мәҗбүри карап тикшерелергә тиеш.

11. Гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе, шулай ук гражданнар җыелышының вәкаләтләре Федераль закон, әлеге Устав һәм Район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

12. Гражданнар җыелышы йомгаклары Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм «Кайбыч таңнары» газетасында рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

19 статья. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы)

1. Халык конференциясе (делегатлар җыелышы) җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча фикер алышу һәм җирлек халкының фикерен ачыклау максатында үткәрелә. Җирлекнең тиешле территориаль өлешләрендә яшәүчеләр арасыннан гражданнарның конференциясе гражданнар җыелышы катлауланганда очракта үткәрелә.

2. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы), делегатлар сайлау әлеге Устав һәм (яисә) Район Советы хокукый акты белән билгеләнә.

3.Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) гражданнар җыелышы вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

4. Халык конференциясе (делегатлар җыелышы) халык, Район Советы, Район Башлыгы инициативасы белән үткәрелә. Район Советы яки Районы Башлыгы инициативасы белән үткәрелгән гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) Район Советы һәм Район Башлыгы тарафыннан билгеләнә. Халык инициативасы белeн үткәрелгән халык конференциясе (делегатлар җыелышы) Район Советы тарафыннан билгеләнә.

5. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы), анда сайланган делегатларның яртысыннан артыграгы катнашса, дөреслеккә туры килә дип санала. Конференция карарлары (делегатлар җыены) конференциядә катнашкан делегатларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча гражданнар (делегатлар җыелышы) конференциясе, әлеге территориядә яшәүчеләрнең өчтән береннән азрак булмаган, 16 яшькә җиткән, гражданнар сайлауларында сайланган делегатларның өчтән икесе катнашса, дөреслеккә туры килә дип санала.

6. Гражданнар конференциясе йомгаклары (делегатлар җыелышы) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм «Кайбыч таңнары» газетасында рәсми рәвештә бастырылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

## 20 статья. Халыктан сораштыру

1. Гражданнар сораштыруы җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлар, шулай ук дәүләт хакимияте органнары тарафыннан карарлар кабул иткәндә, халыкның фикерен ачыклау һәм аны исәпкә алу өчен җирлек территориясендә үткәрелә.

Сораштыру нәтиҗәләре тәкъдим рәвешендә генә була.

2. Гражданнар арасында сорашып белешүдә сайлау хокукына ия булган Район халкы катнашырга .

3. Гражданнарны сораштыру түбәндәге инициативалар буенча үткәрелә:

1) Район Советы яисә Район Башлыгы тарафыннан-җирле әһәмияттәге мәьәләләр буенча;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан – Район җирләрен республика һәм республика әһәмиятендәге объектлар өчен максатчан билгеләнештәге үзгәртү турындагы карар кабул иткәндә гражданнар фикерләрен исәпкә алу өчен.

4. Гражданнарны сораштыру үткәрү һәм билгеләү тәртибе Район Сове-тының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

5. Гражданнарны сораштыру үткәрү турында карар Район Советы тара-фыннан кабул ителә. Район Советы карары нигезендә гражданнарны со-раштыруда түбәндәгеләр билгеләнә:

1) сораштыру үткәрү датасы һәм сроклары;

2) сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган (соруларны) мәсьәләне (мәсьәләләрне) формулировкалау;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазе формасы;

5) сораштыруда катнашучы Район  халыкның минималь саны.

6. Районда яшәүчеләр әлеге чараны уздыруга 10 көннән дә ким булмаган вакыт эчендә гражданнардан сораштыру үткәрү турында мәгълүмат бирергә тиеш.

7. Халык арасында сораштыру әзерләү һәм үткәрү белән бәйле чараларны финанслау түбәндәгеләр хисабына гамәлгә ашырыла:

1) Район бюджеты акчалары исәбеннән – Район  җирле үзидарә органнары инициативасы буенча сораштыру үткәргәндә;

2) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән - Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы буенча сораштыру үткәргәндә.

8. Сораштыру нәтиҗәләре аны үткәргәннән соң бер ай эчендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм «Кайбыч таңнары» газетасында  рәсми рәвештә бастырылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш. Сорашып белешү нәтиҗәләре белән Районның һәр кешесе танышырга хокуклы. Сораштыру нәтиҗәләре җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешле карарлар кабул иткәндә мәҗбүри исәпкә алынырга тиеш.

21 статья. Җирле әһәмияткә ия сораулар турында халык белән фикер алышу

1. Муниципаль хокукый актлар проектлары һәм аеруча әһәмиятле  җирле сорауларны халык белән  фикер алышуга чыгару Район  Советы тарафыннан  үз инициативасы белән яисә Район Советы билгеләгән тәртиптә шул территори-ядә яшәүче гражданнар таләбе белән кабул ителә.

2. Муниципаль хокукый актлар проекты тексты һәм башка материаллар аларны халык белән фикер алышуга чыгару карары чыкканнан соң 5 көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълэмат чараларында бастырыла, Район халкына таратыла, халыкка танышу өчен уңайлы җирләргә урнаштырыла , башка ысуллар белән халыкка җиткерелә .

3. Мәсьәләне халык белән  фикер алышуга  чыгару белән бер үк вакытта, Район Советы  фикер алышу вакыт туачак  тәкъдимнәр һәм кисәтүләр карау-ны оештыру эшенең вакытын һәм тәртибен билгели, моның өчен махсус  комиссия төзи.

4. Район Советы    фикер алышуга чыгарылган  муниципаль хокукый актлар проектлары  һәм башка җирле әһәмияткә ия сораулар  буенча фикерләшү өчен тиешле шартлар тудыра.

5. Халык белән  фикер алышуга  чыгарылган  мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр Район  Советына җибәрелә .

6. муниципаль хокукый актлар проектлары  һәм башка җирле әһәмияткә ия сораулар  буенча  тәкъдимнәр һәм кисәтүләр Район  Советында карала.

7. Халык белән фикер алышу нәтиҗәләре бер ай вакыт эчендә халыкка игълан ителә.

22 статья. Җирле үзидарә органнарына гражданнар мөрәҗәгатьләре

1. Гражданнар Районның җирле үзидарә органнарына индивидуаль һәм күмәк мөрәҗәгатьләргә хокуклы.
2. Гражданнарның мөрәҗәгате 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законында һәм Татарстан Республикасының 2003 елның 12 маендагы 16-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» Законында билгеләнгән тәртиптә һәм срокта карап тикшерелергә тиеш.
3. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе һәм срокларын бозган өчен җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

23 статья. Район халкының җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыруда һәм аны гамәлгә ашыруда катнашуының башка формалары

1. Әлеге Устав белән бергә федераль закон нигезендә җирле үзидарә халкын турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда халык-ның катнашуы формалары белән беррәттән гражданнар җирле үзидарәне Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка рәвешләрдә гамәлгә ашыруда катнашырга хокуклы.
2. Район халкының җирле үзидарәне турыдан-туры тормышка ашыру һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда халыкның катнашуы законлылык, иреклелек принципларына нигезләнә.
Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары халыкка җирле үзидарәне турыдан-туры тормышка ашыруда һәм халыкның җирле үзидарәдә катнашуын тормышка ашыруда ярдәм итәргә тиеш.

## III БҮЛЕК. РАЙОН СОВЕТЫ

24 статья. Район Советы - Район Җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы

1. Район Советы Район җирле үзидарәсенең даими эшләүче сайлау коллегиаль вәкаләтле органы булып тора.
2. Район Советының рәсми атамасы – «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль Район Советы».
3. Район Советы вәкаләтләре срогы – 5 ел.
4. Район Советы Районда яшәүче халык контролендә һәм Район халкына хисап тота.
5. Района Советы Район гербы һәм үз атамасы язылган мөхер, бланкка.

6. Район Советы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары Россия Федерациясе бюджеты чыгымнарын классификацияләү нигезендә җирлек бюджеты өчен аерым юл белән карала.

25 статья. Район Советы Составы

1. Район Советы 34 депутаттан тора.
2. Аның составына Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе сайланганда җирлек Район Советы вәкаләтле була.

26 статья. Район Советы депутатларын статусы сайлау тәртибе

1. Район Советы составына Район составына керүче җирлек башлыклары, һәм күрсәтелгән җирлекләрнең вәкаләтле органнары тарафыннан үз составыннан халкы күпме булуга карамастан һәр җирлектән бер вәкил нигезендә сайланган вәкаләтле органнарының депутатлары.

Район составына керә торган бер җирлек вәкиллеге нормасы Район Советы санының өчтән береннән дә артырга тиеш түгел.

2. Җирлекнең вәкаләтле органы депутатлары арасыннан сайлана торган Район Советы Депутаты, тиешле җирлекнең яңа чакырылыш вәкаләтле органның хокуклы составының, шул исәптән бу чакырылышның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылса, алдагы чакырылыш, беренче утырыш көненнән бер айдан да соңга калмыйча сайланырга тиеш.

3. Район Советына җирлекнең вәкаләтле органы депутатлары арасыннан депутат сайлау яшерен тавыш бирү юлы белән гамәлгә ашырыла һәм әлеге орган карары белән рәсмиләштерелә.

4. Җирлекнең вәкаләтле органының җирлек башлыгы һәм җирлекнең вәкаләтле органы депутатын Район Советы депутаты итеп сайлау турындагы карары өч көн вакыт эчендә Район Советына җибәрелә.

27 статья. Район Советы депутаты статусы

1. Район Советы депутаты вәкаләтләре аны җирлек советы депутатлары арасыннан җирлек башлыгы яки Район Советы депутаты итеп сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш Район Советы эшли башлаган көннән туктатыла.

Федераль законның 35 статьясы 4 бүлеге 1 пункты нигезендә муниципаль район составына керүче, җирлек башлыкларыннан торучы Район Советы депутаты вәкаләтләре, муниципаль район составына керүче җирлек башлыгы вазыйфасына кергән, яки әлеге җирлек депутатының Район Советы депутаты итеп сайланган көннән башлана, һәм яңа сайланган җирлек башлыгы үз вазыйфаларына, яки әлеге җирлекнең Район Советына яңа депутатлар сайлау турындагы карар гамәлгә кергәч туктатыла.

2. Депутат үз эшчәнлеген депутат статусы нигезләмәсе һәм Район Советы Регламенты нигезендә алып бара.

3. Район Советы Депутаты, депутат эшчәнлеген әлеге Устав белән билге-ләнгән очраклардан тыш, төп эш урыны буенча хезмәт һәм хезмәт вазый-фаларын башкару белән бергә, даими булмаган нигездә алып бара.

4. Район Советы депутаты статусы белән бәйле чикләүләр федераль законнар белән билгеләнә.

5. Район Советы депутаты вәкаләтләре срогы Татарстан Республикасы законы нигезендә Район Уставы белән билгеләнә һәм ике елдан азрак, биш елдан күбрәк була алмый.

6. Район Советы депутатына законнар, әлеге Устав, Район Советы карарлары нигезендә үз вәкаләтләрен тоткарлыксыз тормышка ашыру өчен шартлар тудырыла.

7. Район Советы депутатының сайлаучылар белән очрашулары, әгәр аларны оештыру тереклек объектларының эшчәнлеген бозмаса, транспорт яисә социаль инфраструктурага, элемтәгә, җәяүлеләр һәм (яки) транспорт чараларына, я булмаса гражданнарның торак йортларга, транспорт һәм социаль инфраструктура объектларына керү юлына комачау итмәсә, махсус каралаган урыннарда, шулай ук ишегалды эче территорияләрендә үтә. Бу турыда Татарстан Республикасы башкарма власте органнары яки җирле үзидарә органнары хәбәрнамәләре кирәк түгел. Шулай да Район Советы депутаты күрсәтелгән органнарны мондый очрашуларның урыны һәм вакыты турында алдан хәбәр бирергә хокуклы.

8. Район Башкарма комитеты Район Советы депутатына сайлаучылар белән очрашулар үткәрү өчен махсус урыннар, шулай ук депутатка сайлаучылар белән очрашулар үткәрү өчен биналарның исемлеген һәм аларны бирү тәртибен билгели .

9. Район Советы депутатының сайлаучылар белән очрашулары гәвами чаралар рәвешендә Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, пикетлар һәм йөрешләр турындагы канунчылыгы белән билгеләнә.

10. Район Советы депутатының сайлаучылар белән Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр , пикетлар һәм йөрешләр турындагы канунчылыгы нигезендә очрашулар оештыруы һәм үткәрүенә каршы килү, Россия Федерациясе канунчылыгы нигезендә административ җаваплылык белән яный.

11. Район Советы депутаты Район Советы тарафыннан раслана торган депутат этикасы кагыйдәләрен үтәргә тиеш, алар шул исәптән депутатның түбәндәге бурычларын да үз эченә алырга тиеш:

1) депутат статусыннан шәхси яисә аның якын туганнарына кагы-лышлы мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарәорганнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр һәм гражданнар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен файдаланмаска;

2) үз-үзеңне депутат вазыйфаларын объектив башкаруда шик уята алырлык тотудан тыелырга, шулай ук аның абруена яки Район Советы абруена зыян китерерлек низаглы хәлләрне булдырмаска;

3) мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү куркынычы булганда - шәхси мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә китерә яисә Депутат вазыйфаларын объектив башкаруга йогынты ясый алган ситуацияләр - бу турыда билгеләнгән

тәртиптә Район Советына хәбәр итәргә һәм Район Советының әлеге мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салуга юнәлтелгән карарын үтәргә;

4) Район Советында халык алдында чыгыш ясау кагыйдәләрен үтәргә;

5) депутат эшчәнлегенә бәйле булмаган максатларда, Федераль закон нигезендә конфиденциаль характердагы мәгълүматка кертелгән мәгълүматларны, депутат вазыйфаларын башкару белән бәйле рәвештә аңа билгеле булган конфиденциаль характердагы мәгълүматка кертмәскә һәм кулланмаска;

6) депутат вазыйфаларын башкару белән бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан бүләкләүләр (бүләкләр, акчалата бүләк, ссудалар, хезмәтләр күрсәтү, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнарын түләү һәм башка бүләкләүләр) алмаска.

12. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы Район Советы депутаты, түбәндәгеләргә хокуклы:

1) эшкуарлык эшчәнлеге белән шәхсән яки вәкаләтле затлар аша шөгыльләнә ала, коммерция оешмасы идарәсендә яки коммерцияле булмаган оешма идарәсендә (билгеләнгән тәртиптә теркәлгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы, башка муниципаль оешмалар, сәяси партия, профсоюз идарәсеннән, яки башка җәмәгать оешмасы, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, күчемсез милек ияләре ширкәте съезды (конференциясе) гомуми җыелышында катнашудан тыш), федераль законнар белән каралган, әгәр оешма белән Россия Федерациясеканунчылыгы нигезендә җирле үзидарә органы исеменнән идарә итү гамәлгә куелган очраклардан тыш (01.01.2019 гамәлгә керә);

2) укыту, фәнни яки иҗади эшчәнлектән кала, башка түләнә торган эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта әгәр башкасы Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе яки Россия Федерациясе канунчылыгы белән каралмаган булса, укыту, фәнни яки иҗади эшчәнлек бары тик чит дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар исәбеннән генә финанслана алмый .

3) идарә органнары, попечительлек яки күзәтү советлары, башка чит ил коммерцияле, дәүләти булмаган оешма органнары составына һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эшләүче структур бүлекчәләренә, әгәр башкасы Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе яки Россия Федерациясе канунчылыгы белән каралмаган булса, керә ала .

4) мәнфәгатьләр конфликтын кисәтү максатында , җирле үзидарә органында сайлау профсоюз органында хезмәт итүче муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен күрсәтелгән вазыйфалар буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыру вакытында тәкъдим итә алмый.

13. Вәкаләтләрен даими гамәлгә ашыручы Район Советы депутаты, гражданлык, административ яки җинаять эше, я булмаса административ хокук бозу турындагы эш буенча яклаучы яки вәкил сыйфатында (законлы вәкил булу очракларыннан тыш) була алмый.

Район Совет депутатлары вәкаләтләрен гамәлгә кую гарантияләре әлеге Устав белән федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.

14. Район Советы депутаты 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон, 2012 елның 3 мартындагы

230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфалары үтәүче, һәм башка затларның чыгымнары белән керемнәре туры килү контроле турында» Федераль закон, 20013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе чикләреннән тыш урнашкан чит ил банкларында акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклау, счетлар ачу һәм саклау, чит ил финанс инструментлары булдыру һәм куллану турында» Федераль закон нигезендә каралган чикләүләр, тыюларны сакларга, вазыйфаларын үтәргә тиеш.

15. Россия Федерациясе закончалыгы нигезендә керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы вазыйфалар турындагы белешмәнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү, Район Советы депутатының коррупциягә каршы торучанлыгын тикшерү Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер–министры) карары белән Татарстан Республикасы законында каралган тәртиптә эшләнә.

16. Әлеге статьяның 14 нче бүлеге нигезендә тикшерү барышында каралган чикләүләр, тыюларныны үтәмәү фактлары, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон, 2012 елның 3 мартындагы 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфалары үтәүче, һәм башка затларның чыгымнары белән ке-ремнәре туры килү контроле турында” Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе чикләреннән тыш урнашкан чит ил банкларында акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклау, счетлар ачу һәм саклау, чит ил финанс инструментлары булдыру һәм куллану турында» Федераль закон белән каралган вазыйфаларны үтәмәү ачыкланса, Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер–министры) Район Башлыгына, тиешле карар чыгарырга вәкаләтле башка җирле үзидарә сайлау органы вазыйфаи затына , җирле үзидарә органына яки судка Район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

17. Муниципаль вазыйфалар биләүче затларның керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм милек характерындагы вазыйфалар турындагы белешмә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча яки муниципаль хокукый актларда күрсәтелгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә бастырылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

28 статья. Район Советы депутатының Район халкы белән мөнәсәбәтләре

1. Район Советы депутаты сайлаучылар, шулай ук сайлау округы территориясендә урнашкан предприятие, оешмалар, дәүләт һәм башка органнар белән элемтәдә тора.

2. Район Советы депутаты сайлаучылар алдында җаваплы һәм алар алдында үз эше, Район Советы эше турында хисап тота, шулай ук халыкны кабул итүләр үткәрә.

3. Район Советы депутаты җирлек халкының законлы хокукларын, ирекләрен һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча законнарда каралган чаралар күрергә, шул

исәптән алардан кергән тәкъдимнәрне, гаризаларны, шикаятьләрне карарга, алардагы мәсьәләләрне дөрес һәм вакытында хәл итәргә тиеш.

29 статья. Яңа сайланган Район Советы эшен оештыру

1. Яңа чакырылыш Район Советы беренче утырышка, Район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе сайланганнан соң, ун көннән дә соңга калмыйча җыела. Сайлаулардан соң беренче утырыш Район Башлыгы, ул булмаганда – Район Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан чакырыла һәм уздырыла.

2. Район Советының сайлаулардан соң беренче утырышын яңа Район Башлыгы сайланганчы Район Советының иң өлкән депутаты ача һәм алып бара.

30 статья. Район Советы Компетенциясе

1. Район Советы карамагында :

1) Район Уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр һәм төзәтмәләр кертү;

2) Район территориясендә һәркем өчен мәҗбүри кагыйдәләр билгеләү;

3) Район бюджеты проектын карау, раслау һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау, аның үтәлешен тикшереп тору;

4) салымнар һәм җыемнар билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә аларны түләү буенча ташламалар бирү;

5) Районның социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау;

6) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә муниципаль программаларны раслау;

7) Район чикләрен үзгәртү, Районны үзгәртү турында инициатива тәкъдим итү;

8) җирлек референдумы билгеләү;

9) Район Башлыгы сайлау;

10) Район Башлыгы урынбасары сайлау;

11) Район Башлыгы һәм җирле үзидарәнең башка сайлап куела торган вазыйфаи затларына, Район Советы депутатларына, муниципаль хезмәткәрләргә һәм муниципаль оешма эшчеләренә һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, Россия Федерациясенең мәгариф турындагы канунчылыгы һәм Россия Федерациясенең муниципаль хезмәт турында канунчылыгы нигезендә кадрлар әзерләүне оештыру;

12) Район Башкарма комитеты Җитәкчесе сайлау;

13) Район Башкарма комитеты структурасын, аның мөмкин булган хезмәткәрләре санын билгеләү;

14) Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын алмаштыруга конкурс үткәрү тәртибе билгеләү, конкурс комиссиясе әгъзаларын билгеләү;

15) Район Контроль-исәп палатасы турында Нигезләмәне раслау, һәм Район мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы турында Нигезләмәне раслау;

16) Район сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләү;

17) Район чикләрен үзгәртү, Районны үзгәртү буенча тавыш бирү билгеләү;

18)Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасын хокукын тормышка ашыру;

19) Район муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү тәртибен, шул исәптән федераль законнар нигезендә аны хосусыйлаштыру шартларын һәм тәртибен билгеләү; шул исәптән Район Советы тарафыннан расланганнан соң федераль законнар нигезендә аларны хосусыйлаштыру тәртибе, милекне алу, Район Советы белән килештереп яки Район советы карары нигезендә гамәлгә куела торган муниципаль мөлкәт төрләре исемлеген билгеләү;

20) муниципаль предприятиеләрне төзү, үзгәртеп кору һәм бетерү турында карарлар кабул итү тәртибен билгеләү, шулай ук, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәтләре күрсәтүгә тарифларны билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибен билгеләү;

21) җирлекнең муниципаль ара хезмәттәшлек итү оешмаларында катнашу тәртибен билгеләү;

22) Район җирле үзидарә органнары эшчәнлеген матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү тәртибен билгеләү;

23) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен Район үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан башкарылуын контрольдә тоту;

24) Районның территориаль планлаштыру документларын, башка шәһәр төзелеше документларын Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә раслау;

25) гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен, җирле резервларны булдыру һәм алардан файдалану тәртибен билгеләү;

26) Район бюджетыннан җирлекләрнең бюджет дәрәҗәсен тигезләү өчен кирәкле акчаларны бүлеп бирү тәртибен һәм шартларын билгеләү;

27) коммерцияле булмаган оешмалар һәм фондлар формасында коммерцияле булмаган оешмалар төзү турында карарлар чыгару;

28) үзенең массакүләм мәгълүмат чараларын булдыру;

29) Район Уставын һәм Район Советы карарларын аңлату;

30) үз эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча Район Советы Регламенты һәм башка карарлар кабул итү;

31) Район Советы Аппараты турында карар кабул итү;

32) Район Башлыгын отставкага җибәрү турында карар кабул итү;

33) билгеләнгән тәртиптә Районның Контроль-исәп палатасы рәисе һәм әгъзаларын (аудиторлар) билгеләү;

34) муниципаль Районнарны алып баруның федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән каралган башка вәкаләтләре, шулай ук әлеге Устав белән Район Советы Компетенциясенә караган башка вәкаләтләр.

2. Район Советы Район Башлыгы, Район Башкарма комитеты Җитәкчесе, Район Башкарма комитеты эшчәнлеге, Район Башлыгы ведомствосында булган башка җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы, шул исәптән Район Советы куйган башка мәсьәләләрнең чишелеше турындагы еллык хисабын тыңлый.

31 статья. Район Советының эш тәртибе

1. Район Советының эш тәртибе әлеге Устав һәм Район Советы Регламенты белән билгеләнә.

2. Район Советы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр хәл ителә торган утырышлар Район Советы эшчәнлегенең төп формасы булып тора.

3. утырышы сайланган депутатлар санынннан 50 процентан да ким булмаган очракта тулы хокуклы дип санала.

4. Район Советының чираттагы утырышлары кирәк булган саен, ләкин кимендә өч айга бер тапкыр уздырыла. Чираттан тыш утырышлар Район Башлыгы яисә Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән бере инициативасы белән чакырыла.

5. Район Советы утырышлары Район Башлыгы тарафыннан чакырыла. Район Советы депутатлары һәм чакырылган затларга чираттагы утырышның вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында биш көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә, ә чираттан тыш утырыш - аны үткәрүгә кадәр кимендә 1 көн алдан.

6. Район Советының һәр утырышында беркетмә языла. Утырыш беркетмәсенә утырыш үткәрү датасы, вакыты, урыны турында мәгълүмат языла, карала торган барлык мәсьәләләр санап кителә, барлык кабул ителгән карарлар тавыш бирү нәтиҗәләре белән теркәлә. Район Советы утырышы беркетмәсен Район Башлыгы имзалаганнан соң, аның белән Районда яшәүче теләсә кем таныша ала.

7. Район Советы утырышларында һәр депутат бер тавышка ия. Район Советы депутаты Шәхси тавыш бирү хокукын тормышка ашыра. Район Советы утырышларында тавыш бирү ачык (шул исәптән исемле) һәм яшерен булырга мөмкин. Тавыш бирүнең һәр төрен куллану очраклары әлеге Устав, Район Советы Регламенты белән билгеләнә.

32 статья. Район Советы эшчәнлеген оештыру

1. Район Советы эшчәнлеген оештыруны Район Башлыгы тормышка ашыра.

2. Район Советы Регламенты нигезендә Район Советы вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү өчен, Район Советы эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча депутатлар арасыннан, Район Башлыгы һәм аның урынбасарларыннан тыш, даими комиссияләр төзелә һәм (яисә) әлеге мәсьәләләрне әзерләү өчен җаваплы депутатлар билгеләнә ала.

3. Муниципаль программалар, Район Советы карарлары проектларын әзерләү, җирлек карамагына караган иң мөһим мәсьәләләр турында фикер алышу өчен Район Советы каршында депутатлар, Район Башкарма комитеты, иҗтимагый берләшмәләр, оешма һәм предприятиеләр, белгечләр, экспертлар һәм җирлек халкы составындагы эшче, эксперт төркемнәре төзелә ала.

4. Район Советы эшчәнлеген оештыру, аны хокукый, мәгълүмати, матди-техник һәм башка яктан тәэмин итүне Район Советы Аппараты башкара.

33 статья. Җирлек Советының контроль функцияләр башкаруы

1. Район Советы Район территориясендә Район Советы тарафыннан кабул ителгән норматив актларның, Район бюджеты үтәлеше, бюджеттан тыш фонд акчаларын куллануны, Районның үсеш программалары үтәлешен, Район Башкарма комитеты һәм аның җитәкчесе эшчәнлеген контрольдә тота.

2. Район Советы җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан законнар, әлеге Устав һәм башка муниципаль хокукый актлар бозу фактлары ачыкланган очракта, Район Советы карары белән, Район Башлыгы депутатлардан әлеге фактларны тикшерү өчен вакытлы контроль комиссияләр барлыкка килергә мөмкин.

3. Район Советы, Район Башлыгы карары белән җирлек бюджеты акчаларын максатчан файдалану, муниципаль милекне файдалануның нәтиҗәлелеге, шулай ук җирлекнең финанс-хуҗалык эшчәнлегендәге башка мәсьәләләр буенча тикшерүләр (ревизияләр) үткәрелә ала. Тикшерүләр (ревизияләр) үткәрүгә билгеләнгән тәртиптә бәйсез аудиторлар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белгечләре җәлеп ителә ала.

4. Район Башкарма комитеты, предприятие, учреждение, оешма, вазыйфаи затлар, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, әгәр законда башкасы билгеләнмәгән булса, Район Советы мөрәҗәгате, аның контроль комиссиясе, Район Советы депутаты гозере белән Район Советы карамагына кагылышлы мәсьәләләр буенча, ә законнарны, муниципаль хокукый актларны бозган очракта, хокук бозуларны бетерү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту буенча кичекмәстән чаралар күрергә тиеш.

5. Район Советы, контроль функцияләр башкарганда, Район Башкарма комитетының финанс-хуҗалык һәм башкару-боеру эшчәнлегенә тыкшынырга хокуксыз.

34 статья. Район Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Район Советы вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

1) Район Советы үз-үзен таркату турында Карар кабул итсә;

2) Район Советын 2003 елның 6 октябрендә 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 73нче статьясы тәртибендә һәм нигезендә таратканда;

3) Җирлек Советы депутатларының әлеге составының хокуксыз булуы турында Татарстан Республикасы Югары судының карары үз көченә керү, шул исәптән депутатларның үз вәкаләтләреннән китүенә бәйле рәвештә;

4) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 13 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору очрагында, шулай ук Район бетерелгәндә;

5) Район чикләре үзгәрү сәбәпле, Районда сайлаучылар саны булган сайлаучылар санының 25 процентыннан да артып китсә;

6) гражданнарның теләкләрен турыдан-туры белдерү юлы белән карарны гамәлгә кую өчен кирәкле муниципаль норматив- хокукый акт чыгарылу срогы бозылса.

2. Җирлек Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату депутатларның да вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуга китерә.

3. Җирлек Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан очракта, җирлекләрнең вәкаләтле органнары бер ай эчендә Район Советы составына башка депутатларны сайларга тиеш.

35 статья. Район Советы үз-үзен таркату турында Карар кабул итү түртибе

1. Район Советының үз-үзен таркату турындагы карар Район Башлыгы яисә Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә яртысы инициативасы белән кабул ителергә мөмкин.

2.Район Советының үз-үзен таркату турында карар кабул итү инициативасын күрсәтә алмау очраклары:

1) Район Советы сайланганнан соң беренче ел дәвамында;

2) Район бюджетын кабул итү һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау чорында;

3) Район Башлыгын чакыртып алу турында тавыш бирүне уздыру чорында, яисә үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан очракта.

3. Район Советының үз-үзен таркату турындагы язма тәкъдимендә үз-үзен таркату мотивлары булырга тиеш, шулай ук аңа үз-үзен таркату сәбәпләрен нигезләүче башка материаллар да беркетелергә мөмкин.

4. Депутатлар арасыннан үз-үзен таркату турындагы мәсьәләне алдан карау өчен Район Советы карары белән комиссия төзелә. Район Советы яки Район Башлыгы карары белән Район Советының үз-үзен таркату турындагы карары халык алдында тыңлауларга чыгарылырга мөмкин.

5. Район Советының үз-үзен таркату турындагы мәсьәләне карау дәвамлылыгы Район Советы депутатлары һәм Район халкы белән үз-үзен таркату инициативасының барлык шартларын һәм нигезләүләрен төрле яклап һәм объектив тикшерү мөмкинлеген гарантияләргә тиеш. Карар үз-үзен таркату турында инициативаны тәкъдим иткән көннән ике ай үткәннән соң кабул ителергә мөмкин.

6. Район Советының үз-үзен таркату турындагы карары яшерен тавыш бирү юлы белән Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан өчтән икесе тавышы белән кабул ителә.

7. Үз-үзен таркату турындагы тәкъдимнәрне Район Советы кире каккан очракта, үз-үзен таркату турындагы инициатива кабат тавыш биргән көннән бер елдан соң гына тәкъдим ителергә мөмкин.

36 статья. Район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Район Советы депутаты вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үлем;

2) үз теләге белән отставкага җибәрү ;

3) суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки эшкә чикләнгән сәләтле дип тану;

4) Суд тарафыннан кайда булуы билгесез дип тану, яки үлгән дип игълан итү;

5) аңа карата судның гаепләү карары үз көченә керү;

6) даими яшәү урынына Россия Федерациясе чикләреннән чыгу;

7) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылу, чит ил гражданлыгы туктатылу - аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органына сайланган булырга, чит ил гражданлыгы алырга яки Россия Федерациясе гражданинының Россия Федерациясе халыкара килешүе катнашучысы булмаган чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документ алырга хокуклы, җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклы;

8) сайлаучылары тарафыннан Район составына керүче җирлекнең вәкаләтле органы депутаты буларак чакыртып алынуы;

9) Район Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату, йә Район Башлыгы буларак яисә вәкаләтле орган депутаты буларак вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

10) хәрби хезмәткә чакыру яисә аны алмаштыра торган альтернатив граждан хезмәтенә җибәрү;

11) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон яисә башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне үтәмәү;

12) 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым категорияләрдәге затларның аерым категорияләренә счет ачуны һәм аларны саклауны тыю турында» Федераль закон белән Россия Федерациясе территориясендә урнашкан чит ил банкларында урнашкан акчалар һәм кыйммәтләрне сакларга һәм, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану» Федераль законнары белән билгеләнгән чикләүләрне үтәмәү;

13) федераль законнар белән билгеләнгән башка очракларда.

2. Район Советы депутаты вәкаләтләрен туктату турындагы карар әлеге статьяның 1нче бүлеге, 1-7 пунктларында күрсәтелгән очракларда Район Советы тарафыннан кабул ителә, анда депутат вәкаләтләрен туктату көне күрсәтелә. Район Советы депутаты вәкаләтләрен туктату турындагы карар Район Советы тарафыннан вәкаләтләрне алдан туктатуга нигез барлыкка килүдән 30 көннән дә соңга калмыйча чыгарыла, әгәр дә бу нигез Район Советы утырышлары арасында булса – нигез барлыкка килүдән башлап 3 айдан соңга калмыйча.

3. Район Советы депутаты вәкаләтләре әлеге статьяның 1нче бүлеге, 8пунктында каралган очракка туры килсә, депутат вәкаләтләрен туктату турында тавыш бирү рәсми рәвештә бастырылган көннән туктатыла.

4. Район Советы депутаты вәкаләтләре әлеге статьяның 1нче бүлеге, 9пунктында каралган очракка туры килсә, Район Башлыгы буларак яисә вәкаләтле органы депутаты буларак вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату вакытыннан алда вәкаләтләрне туктату көненнән гамәлгә куела.

5. Район Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта,1ай эчендә тиешле җирлекнең вәкиллек органы депутатлары арасыннан Район Советы составына икенче депутат сайлана.

6. Район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер-министры) гариза белән мөрәҗәгать итсә, бу гариза Советка килгән көн вәкаләтләрне алдан туктатуга нигез барлыкка килгән көн булып санала.

## IV Бүлек. РАЙОН БАШЛЫГЫ

### 37 Статья. Район Башлыгы - Районның иң югары вазыйфаи заты.

1. Район Башлыгы Районның иң югары вазифаи заты булып тора.

2. Район Башлыгы Район Советы тарафыннан сайлана һәм тавыш бирү хокукы белән рәисе вәкаләтләрен үти.

3. Район Башлыгының рәсми атамасы - «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы» .

### Статья 38. Район Башлыгын сайлау тәртибе

1. Район Башлыгы яңа сайланган Район Советының беренче утырышында, әгәр Район Советы башка тавыш бирү тәртибе кертмәсә, Район Советы депутатлары арасыннан яшерен тавыш бирү юлы белән, Район Советы вәкаләтләре срогына сайлана. Район Башлыгы Район Советы депутатлары тәкъдиме белән, шул исәптән Район халкы, җәмәгать берләшмәләре, Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәре нигезендә сайлана.

2. Сайлау өчен Район Советы депутатларының билгеләнгән санынның яртысыннан артыграгы тавыш бирсә, Район Советы депутаты Район Башлыгы тарафыннан сайланган дип санала.

### 39 статья. Район Башлыгы Статусы

1. Район Башлыгы даими нигездә эшли.

2. Район Башлыгы федераль закон һәм әлеге Устав нигезендә Район халкы һәм Район Советы контролендә һәм алар алдында хисап тота.

3. Район Башлыгы кимендә елга бер тапкыр Район Советы алдында үз эшчәнлеге турында хисап тота.

4. Район Башлыгы 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон, 2012 елның 3 мартындагы 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфалары үтәүче, һәм башка затларның чыгымнары белән керемнәре туры килү контроле турында» Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе чикләреннән тыш урнашкан чит ил банкларында акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклау, счетлар ачу һәм саклау , чит ил финанс инструментлары булдыру һәм куллану турында» Федераль закон нигезендә каралган чикләү, тыюларны җиренә җиткереп сакларга, вазыйфаларны үтәргә тиеш.

5. Район Башлыгы түбәндәгеләргә хокукы юк:

1) Шәхси яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, шулай ук хуҗалык итүче субъект (торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларыннан, күчемсез милек хуҗалары һәм профсоюзның билгеләнгән тәртиптә теркәлгән иптәшлекләреннән, әгәр федераль законнарда башкача каралмаган булса ,Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләреннән тыш) белән идарә итүдә катнашырга, шул исәптән әлеге оешма белән идарә итү Россия Федерациясе канунчылыгы нигезендә җирле үзидарә органы исеменнән башкарылса;

2) укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүе яки Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, фәкать чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;

3) Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә итү органнары, Попечительләр яки күзәтү советлары, чит илләрнең коммерцияле булмаган оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган структур бүлекчәләре составына керергә.

Район Башлыгы гражданлык, җинаять яисә административ хокук бозулар буенча яклаучы яки вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш), була алмый.

Район Башлыгына Россия Федерациясе чикләреннән тыш урнашкан чит ил банкларында акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклау, счетлар ачу һәм саклау, чит ил финанс инструментлары булдыру һәм куллану тыела.

Район Башлыгына вәкаләтләрен тормышка ашыру федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге Устав белән билгеләнә.

40 статья. Район Башлыгы вәкаләтләре

Район Башлыгы:

1) Район исеменнән башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалары белән мөнәсәбәтләрдә эш йөртә, Район исеменнән ышанычнамәсез эш итә;

2) Район Советы эшчәнлеген оештыра, Район Советы утырышларын чакыра һәм аларда рәислек итә;

3) Район Советы кабул иткән норматив хокукый актларга әлеге Устав белән билгеләнгән тәртиптә имза сала һәм халыкка хәбәр итә;

4) Район Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча үз вәкаләтләре чикләрендә хокукый актлар чыгара;

5) Район Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт төзи;

6) Район Советы эшендә җәмәгатьчелек фикерен, хәбәрдарлыкны исәпкә алуны тәэмин итү буенча чаралар күрә;

7) гражданнарны шәхси кабул итүне гамәлгә ашыра һәм гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне карый;

8) Район Советы утырышлары беркетмәләрен имзалый;

9) Район Совета Аппараты белән ҹитәкчелек итә;

10) Район Советының контроль вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны координацияли;

11) Район бюджетында Район Советы эшчәнлеген тәэмин итүгә каралган чыгымнар буенча акча бүлүче булып тора;

12) Закон һәм әлеге Устав нигезендә гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерүләре юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру буенча Район советының хокукый актын кабул итүне оештыра;

13) Район җирле үзидарә органнарының федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, башка федераль органнар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән җирлек территориясендә гамәлдә булган үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

14) Район исеменнән икътисадый һәм социаль-мәдәни өлкәләрдә хезмәттәшлек турында дәүләт хакимияте органнары, башка муниципаль берәмлек-ләрнең җирле үзидарә органнары белән шартнамәләр һәм килешүләр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән үзара эшчәнлек турында шартнамәләр һәм килешүләр төзи ;

15) муниципаль хезмәткәрләрнең һәм Район үзидарә органнары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү күләмен һәм шартларын билгели;

16) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

17) 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт-шәхси партнерлыгы, муниципаль –шәхси партнерлык һәм аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә муниципаль –шәхси партнерлык өлкәсендә вәкаләтләрне тормышка ашыру вәкаләтенә ия булган җирле үзидарә органын билгели;

18) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән Район Башлыклары карамагына кертелгән башка вәкаләтләрне, әлеге Устав, Район Советы карарлары белән Район Башлы вәкаләтләренә кертә.

41 статья. Район Башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Район Башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату түбәндәге очракларда тормышка ашырыла:

1) үлем;

2) үз теләге белән отставкага җибәрү;

3) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 74.1нче статьясы тәртибендә отставкага китү;

4) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 74 нче статьясы нигезендә вазыйфасыннан ваз кичү;

5) суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки эшкә чикләнгән сәләтле дип тану;

6) Суд тарафыннан кайда булуы билгесез дип тану, яки үлгән дип игълан итү;

7) аңа карата судның гаепләү карары үз көченә керү;

8) даими яшәү урынына Россия Федерациясе чикләреннән чыгу;

9)Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылу, чит ил гражданлыгы туктатылу - аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланган булырга, чит ил гражданлыгы алырга яисә аларга Россия Федерациясе гражданинының Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашмаган чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документ алырга, җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклы;

10) сайлаучылары тарафыннан Район составына керүче җирлекнең вәкаләтле органы депутаты буларак чакыртып алынуы;

11) суд тәртибендә урнаштырылган сәламәтлек торышы буенча Район Башлыгы вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга сәләтсезлек;

12) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 13нче статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла торган Районны үзгәртеп кору;

13) Район чикләрен үзгәрткәннән соң, сайлаучылар саны 25 проценттан күбрәккә арткан очракта;

14) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне үтәмәү;

15) 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым категориялəрдәге затларның аерым категорияләренә счет ачуны һәм аларны саклауны тыю турында» Федераль закон белән Россия Федерациясе территориясендә урнашкан чит ил банкларында урнашкан акчалар һәм кыйммәтләрне сакларга һәм, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану» федераль законнары белән билгеләнгән чикләүләрне үтәмәү.

2. Район Башлыгы вәкаләтләре Россия Федерациясе Президенты ышанычын югалткан түбәндәге очракта шулай ук вакытыннан алда туктатыла:

- Район Башлыгы, тормыш иптәше балигъ булмаган балалары тарафыннан 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым категорияләрдәге затларның аерым категорияләренә счет ачуны һәм аларны саклауны тыю турында» Федераль закон белән Россия Федерациясе территориясендә урнашкан чит ил банкларында урнашкан акчалар һәм кыйммәтләрне сакларга һәм, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану» федераль законында каралган тыюларны үтәмәү.

3. Район Башлыгы вәкаләтләре әлеге статьяның беренче өлеше 1-10 пунктларында каралган нигездә вакытыннан алда туктатылса, яңа Район Башлыгы сайлау вәкаләтләрне туктатудан алты айдан да соңга калмыйча тормышка ашырыла.

Әгәр Район Советы вәкаләтләре чыгуга алты айдан азрак вакыт калган икән, Район Башлыгы яңа сайланган Җирлек Советының беренче утырышында башкарыла.

4. Район Советы карары белән отставкага җибәрү карары чыгарылган Район Башлыгы, мондый карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарылганнан соң ун көн эчендә әлеге карарны яңадан карау соравы белән судка мөрәҗәгать итә ала. Суд гаризаны кабул иткәннән соң 10көннән дә соңга калмыйча карар чыгарырга тиеш.

5. Әгәр вәкаләтләре Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер-министры ) хокукый акты нигезендә, я Район Советы карары белән вакытыннан алда туктатылган Район Башлыгы бу карарны суд карары белән кире кага икән, Район Советы суд карары законлы көченә кермичә Район башлыгы сайлау турында карар кабул итә алмый.

## 42 нче статья. Район Башлыгы урынбасары

1. Район Башлыгы тәкъдиме белән Район Советы депутатлары арасыннан Район Башлыгы урынбасары сайлана.

Район Башлыгы урынбасары яшерен яки ачык тавыш бирү юлы белән сайлана.

2. Район Советы депутаты, аның сайлануы өчен билгеләнгән депутатлар санының яртысыннан артыгы тавыш бирсә сайланган Район Башлыгы урынбасары дип санала.

3. Район Башлыгы урынбасары Район Советы Регламенты белән билгеләнгән вазыйфалар нигезендә эшли,Район Башлыгы кушкан йөкләмәләрне үти.

Район Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылса, я процессуаль суд чаралары белән сак астына алынса яки вакытлыча вазыйфасыннан алынса, вакытлыча булмаса (авыру яки чираттагы ялы аркасында ) яки вәкаләтләрен үтәү мөмкинлеге булмаса, аның вәкаләтләрен вакытлыча Район Башлыгы урынбасары башкара.

4. Район Башлыгы Район Советына урынбасарын даими нигездә сайларга тәкъдим итәргә хокуклы.

4. Район Башлыгы урынбасары вәкаләтләре әлеге Уставның 35 статьясында каралган нигездә вакытыннан алда туктатыла.

5. Район Башлыгы урынбасары Район Башлыгы инициативасы, я булмаса Район Советы депутатларының билгеләнгән санының өчтән бере таләбе нигезендә Район Советы карары белән теләсә кайсы вакытта вазыйфасыннан чыгарыла ала. Район Башлыгы урынбасарын вазыйфасыннан азат итү турындагы карар Район Советы депутатларының күпчелеге тавышы белән хәл ителә.

6. Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы Район Советы урынбасарының түбәндәгеләргә хокукы юк:

1) Шәхси яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, шулай ук хуҗалык итүче субъект (торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларыннан, күчемсез милек хуҗалары һәм профсоюзның билгеләнгән тәртиптә теркәлгән иптәшлекләреннән, әгәр федераль законнарда башкача каралмаган булса, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләреннән тыш) белән идарә итүдә катнашырга, шул исәптән әлеге оешма белән идарә итү Россия Федерациясе кануничылыгы нигезендә җирле үзидарә органы исеменнән башкарылса;

2) укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүе яки Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, фәкать чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;

3) Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә итү органнары, Попечительләр яки күзәтү советлары, чит илләрнең коммерцияле булмаган оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган структур бүлекчәләре составына керергә.

Район Башлыгы урынбасары гражданлык, җинаять яисә административ хокук бозулар буенча яклаучы яки вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш), була алмый.

7. Район Башлыгы урынбасары 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон, 2012 елның 3 мартындагы 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфалары үтәүче, һәм башка затларның чыгымнары белән керемнәре туры килү контроле турында» Федераль закон, 20013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе чикләреннән тыш урнашкан чит ил банкларында акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклау, счетлар ачу һәм саклау, чит ил финанс инструментлары булдыру һәм куллану турында» Федераль закон нигезендә каралган чикләүләр, тыюларны сакларга, вазыйфаларын үтәргә тиеш.

8. Район Башлыгы урынбасары вәкаләтләрен тормышка ашыру гарантияләре федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге Устав белән билгеләнә.

## V Бүлек. РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

### 43 Статья. Район Башкарма комитеты - Районның башкарма-боеру җирле үзидарә органы

1. Район Башкарма комитеты - Районның башкарма-боеру җирле үзидарә органы булып тора.

2. Район Башкарма комитетының рәсми атамасы – «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль Районы Башкарма комитеты», кыскача атамасы – «Район Башкарма комитеты».

3. Район Башкарма комитеты сайлаучылар Район Советы, Район Башлыгы һәм Район халкы алдында җаваплы һәм алар алдында хисап тота.

4. Район Башкарма комитеты мөхер, Район гербы сүрәтләнгән, үз атама-сы язылган бланк, шулай ук гражданлык мөнәсәбәтләре акты турында дәүләт регистрациясе ясау өчен бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә кую өчен Россия Федерациясе гербы сурәтләнгән түгәрәк мөхергә ия.

5. Район Башкарма комитеты эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары Россия Федерациясе бюджеты чыгымнарын классификацияләү нигезендә җирлек бюджеты өчен аерым юл белән карала.

### 44 статья. Район Башкарма комитеты структурасы

1. Район Башкарма комитеты структурасы Район Башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе белән Район Советы тарафыннан раслана.

2. Район Башкарма комитеты структурасына Район Башкарма комитеты җитәкчесе, аның урынбасарлары, өлкә (функциональ) һәм (яисә) Район Башкарма комитеты территориаль органнары керә.

45 статья. Район Башкарма комитеты вәкаләтләре

1. Район Башкарма комитеты:

1) планлаштыру, бюджет, финанлар һәм хисап өлкәсендә:

- Район бюджеты проектын төзүне тәэмин итә (бюджет проекты һәм уртача сроклы финанс планы);

- Район Советына тиешле документлары һәм материаллары белән Район бюджеты проектын раслауга куя (бюджет проекты һәм уртача сроклы финанс планы);

-Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә бюджетара трансфертларны бүлү һәм (яисә) бирү методикаларын эшкәртә һәм раслый;

- Района бюджетын һәм бюджет хисабы төзүне тәэмин итә, Район бюджеты үтәлеше турында хисапны Район Советына раслауга куя;

- муниципаль бурыч белән идарә итә;

- Района бюджеты үтәлешен оештыра;

- Районның икътисади һәм социаль торышын характерлаучы статистик күрсәткечләр җыюны оештыра һәм күрсәтелгән мәгълүматларны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына тапшыруны оештыра;

- Район бюджеты чаралары исәбеннән җирлекләрнең бюджет дәрәрҗәләре тигезләнешен тәэмин итә;

- Район Советы карары нигезендә муниципаль кыйммәтле кәгазьләр чыгару, кредитлар алу, муниципаль гарантияләр бирү юллары белән муниципаль бурыч алуларны гамәлгә куя һәм муниципаль милекне закладка сала;

- 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» Федераль законында каралганча стратегик планлаштыру өлкәсендә вәкаләтләрне тормышка ашыра ;

2) муниципаль милек белән идарә итү өлкәсендә , Район территориясендә булган предприятие, учреждение һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр:

- Район муниципаль милкендә булган милек белән идарә итә, муниципаль милек объектларын булдыру, файдалану, идарә итү һәм арендалау мәсьәләләрен хәл итә;

-Район Советы карары белән билгеләнгән очракларда Район Советы килешүенә (раславына) муниципаль милекне тартып алу, шул исәптән аны хосусыйлаштыру турында тәкъдимнҗр әзерли һәм кертә;

- Район Советы билгеләгән тәртип нигезендә муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр булдыра, аларның эшчәнлегенең максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели, уставларын раслый, муниципаль казна учреждениеләрен финанслауны һәм бюджет һәм автоном муниципаль учреждениеләрнең муниципаль мәсьәләләрне үтәвенең финанс ягын тәэмин итә;

- муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, оешмалар белән җирлекнең икътисадый һәм социаль үсеше турында килешүләр төзи; Район

территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә төрле милек формасындагы предприятиеләр булдыруга ярдәм итә;

- муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итүче товарлар, эш һәм хезмәт күрсәтүне сатып алуны тормышка ашыра;

-бюджет һәм автоном муниципаль учреждениеләрнең муниципаль мәсьәләләрне үтәвенең финанс ягын тәэмин итә;

- муниципаль предприятие һәм учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү размерын һәм шартларын билгели;

- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль предприятие һәм учреждениеләр күрсәтә торган хезмәтләр өчен Район Советы билгеләгән тәртиптә тарифлар билгели;

- коммуналь инфраструктура системасына кертү, коммуналь комплекс оешмалары тарифларына кертү тарифларын, коммуналь комплекс оешмалары товарлары һәм хезмәтләре тарифларына өстәмәләр, куллану-чылар өчен бәяләргә (тарифларга) өстәмәләрне көйли;

- хезмәт күрсәтелүче административ Район участогы полиция участок уполномоченные вазыйфасын башкаручы хезмәткәргә эш урыны өчен бүлмә бирә;

- 2017 елның 1 гыйварына кадәр полиция участок уполномоченные вазыйфасын башкаручы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына бу вазыйфасы буенча хезмәт күрсәткән чорга торак урын бирү;

- депутатларга сайлаучылар белән очрашу өчен махсус каралаган урыннар билгели, шулай ук депутатларга сайлаучылар белән очрашу өчен

биналарның исемлеге һәм аларны бирү тәртибен билгели ;

3) территориаль планлаштыру, җирне һәм башка табигый ресурсларны файдалану, әйләнә-тирәлекне саклау өлкәсендә:

- Районны территориаль планлаштыру документлары проектлары, башка шәһәр төзелеше документациясе проектын эшли һәм Район Советына раслауга кертә, аларны тормышка ашыруны тәэмин итә;

- Район территориясендә тормышка ашырыла торган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүче мәгълүмат системасын булдыра;

- законнар белән билгеләнгән тертиптә Район территориясендә җир участокларын бирә һәм ала;

- Районның авылара территориясендә муниципаль җир контролен тормышка ашыра;

- халыкны экологик хәл белән таныштыра, тиешле органнарга әйләнә-тирәгә куркыныч тудыручы, табигать белән куллану канунчылыгын бозучы предприятие, учреждение, оешмалар турында хәбәр итә;

- әйләнә-тирә табигатьне саклау буенча авылара чаралар оештыра;

- Район территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шулай ук аерым җыю), күчерү, эшкәртү, юкка чыгару, зарарсызландыру, күмү эшләрен оештыра (2019 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә);

- Район территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм курортларны булдыра, үстерә һәм саклауны тәэмин итә, шулай

ук җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклануча табигый территорияләрне куллану һәм саклауны муниципаль контрольләүне гамәлгә ашыра;

- Россия Федерациясе су канунчылыгы һәм су объектлары милекчесе вәкәләтләре чикләрендә су объектларын гомуми куллануның, гражданнарның су объектларын һәм аларның яр полосаларын ирекле куллануын кертеп, шәхси һәм көнкүреш кагыйдәләрен билгели;

- муниципаль урман контролен тәэмин итә;

- Район ихтыяҗы өчен ясалма җир участоклары булдыру эшләре тәэмин итә, федераль закон нигезендә ясалма җир участоклары ясау эшләре буенча шартнамә төзүгә ачык аукцион үткәрә;

- авыл җирлекләре чикләрендә 2007 елның 24 июнендәге 221-ФЗ номерлы «Кадастр эшчәнлек турында» Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләре оештыра һәм территориянең карта-планын төзи;

- җирлекнең генераль планын, җирдән куллану һәм төзү кагыйдәләрен, территорияне планлаштыру буенча җирлекнең генераль планы нигезендә әзерләнгән документацияне раслый, төзелеш эшенә рөхсәт бирә (Россия Федерациясе Шәһәртөзү кодексында каралган очраклардан, башка законнардан кала), җирлек территорияләрендә урнашкан капиталь төзелешь объектларын эксплуатацияләүгә рөхсәт бирә ,җирлек территориясен проектлауның урындагы нормативларын раслый, җирлек чикләрендәге җир кишәрлекләрен муниципаль ихтыяҗлар өчен резервка калдыру һәм алу, җирлек чикләрендә муниципаль җир контролен тормышка ашыра, хәбәрнамә нигезендә күрсәтелгән планлаштырылган индивидуаль торак яки бакча йорты төзү планлаштыруны бу кишәрлеккә куелган параметрлар нигезендә башкара, Россия Федерациясе Шәһәртөзү кодексы нигезендә корылма, зданиеләрне карый, шундый караулар барышында ачыкланган канун бозуларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр бирә, хәбәрнамә нигезендә һәм бу җиргә индивидуаль торак яки бакча йорты төзү ярамауны белдерә, муниципаль җирлек территориясендә төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак яки бакча йорты шәһәртөзү эшчәнлеге турында шартларга туры килү-килмәве турында хәбәрнамә бирә, Россия Федерациясе гражданлык канунчылыгы нигезендә авылара территориләрдә рөхсәтсез төзелгән корылмаларны юкка чыгара, авылара территориләрдә рөхсәтсез төзелгән корылмаларны юкка чыгару яки куелган таләпләргә яраклаштыру турында хәбәрнамәләр бирә, гамәлгә куелган җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, территорияне планлаштыру документациясен тикшерүне, җирлек территорияләрендә Россия Федерациясе канунчылыгына каршы килеп кулланылучы яки максатчан кулланылмаучы җир кишәрлекләрен алу турында хәбәрнамә бирә, авылара территориләрдә рөхсәтсез төзелгән корылмаларны юкка чыгару яки куелган таләпләргә яраклаштыруны Россия Федерациясе Шәһәр төзү кодексы нигезендә гамәлгә ашыра;

- Россия Федерациясе законнарына ярашлы итеп, торак пунктлар чикләрендә торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек, җирле әһәмияткә ия булган юлларның сакланышы, юл хәрәкәтен оештыру, юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү, шулай ук

автомобиль юллары өлкәсендә башка вәкәләтләрне һәм юл эшчәнлеген тормышка ашыра;

4) төзелеш, транспорт һәм элемтә өлкәсендә:

- Район территориясендә торак төзелеше өчен шартлар тудыра;

- Россия Федерациясе законнарына ярашлы итеп (30.12.2018 үз көченә керә), торак пунктлар чикләрендә торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек (парковка урыннары булдыру һәм аларны эшләтүне тәэмин итүне дә кертеп), җирле әһәмияткә ия булган юлларның сакланышы, юл хәрәкәтен оештыру, юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү, шулай ук автомобиль юллары өлкәсендә башка вәкәләтләрне һәм юл эшчәнлеген тормышка ашыра;

- Район чикләрендә торак пунктлар арасында транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыра;

- Район чикләрендә җәмәгать транспорты туктау өчен торак пункт чикләрендә булмаган урыннарны төзекләндерүне тәэмин итә;

- җирлекләрне элемтә хезмәте белән тәэмин итүгә шартлар тудыра;

5) халыкка торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә:

- энергия саклау һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру буенча муниципаль программаларны гамәлгә;

- биналары Район чикләрендәге муниципаль торак фондын тәшкил итүче күпфатирлы йортларны энергетик тикшерү; энергия сауклау һәм энерге-тик нәтиҗәлелекне арттыру буенча канунчылык белән каралаган башка чараларны оештыра;

- Район чикләрендә җирлек халкын электр һәм газ белән тәэмитн итә;

- 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы «Су белән һәм су кертү белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәмин итүне оештыра;

- 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы «Җылылык белән тәэмин итү турында» Федераль закон нигезендә, җылылык белән тәэмин итү вәкаләтләрен үти;

- Район составына кергән җирлекләрдә яшәүчеләрне элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

- халыкка авылара китапханә хезмәте күрсәтүне, китапханә фондларын комплектлау һәм саклауны оештыра;

- ритуаль хезмәтләр күрсәтү һәм авылара күмү урыннарын тотуны тәэмин итә;

- Район составына кергән җирлекләрдә урындагы традицион иҗат өчен шартлар булдыра;

- муниципаль Район составына кергән җирлекләрдә ялны оештыру һәм мәдәни оешмалар хезмәте булдыруга шартлар тудыра;

- җирлекләрдә авыл хуҗалыгы үсеше өчен шартлар тудыра, авыл хуҗалыгы продукциясе, азык-төлек һәм чимал базарын киңәйтә, кече һәм урта эшкуарлык

үсешенә, социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмаларга, волонтерлыкка, иганәчелек эшчәнлегенә ярдәм күрсәтә;

- Район территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсешенә шартлар булдыра, Районның рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыра;

- Район территориясендә реклама конструкцияләре кую, аларны куюга рөхсәт бирә, мондый рөхсәт бирүләрне юкка чыгарә, рөхсәтсез урнаштырылган реклама конструкцияләрен алдыру турында күрсәтмәләр бирүне 2006 елның 13 мартындагы «Реклама турында» Федераль закон нигезендә гамәлгә ашыра;

- Район территориясендә урнашкан, Район милкенә караган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклый, куллана һәм популярлаштыра;

6) мәгариф һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә:

- муниципаль гомумбелем ошмаларында төп гомуми белем программалары буенча һәркемгә кулай һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне (федераль дәүләт белем стандартларын гамәлгә ашырудан тыш финанслаудан кала), муниципаль гомумбелем ошмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыра (балаларга өстәмә белем бирүне финанслау дәүләт власте органнары (Татарстан Республикасы) тарафыннан оештырыла торган өстәмә белем бирүдән кала), балаларны карауны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра, муниципаль гомумбелем ошмаларында балаларны тота, шулай ук каникуллар вакытында үз вәкәләтләре чикләрендә балаларның тормышын һәм саулыгын түэмин итү чараларын кертеп ялын оештыра ;

- Район территориясендә яшәүчеләргә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләре территориаль программасы нигезендә, медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыра (Россия Федерациясе Хакимияте тарафыннан расланган аерым территорияләрдә яшәүчеләргә башкарма властьның федераль органнарына хезмәт күрсәтүче медик-санитар хезмәте тарафыннан медицина ярдәме күрсәтелә торган территорияләр исемлегенә кергәннәрдән кала);

- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча авылара характердагы чараларны оештыра һәм тормышка ашыра;

7) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау, законлылыкны тәэмин итү, Халыкны һәм территорияне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә:

- Район территориясендә законнарның, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары актларының үтәлешен, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклауны тәэмин итә;

- билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән судта яки арбитраж судында, җирле үзидарә хокукларын боза торган дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт вазыйфаи затлары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар актларына шикаять бирә;

- җирлек чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итә;

- Район чикләрендә гадәттән тыш хәлләр турында кисәтү һәм аның нәтиҗәләрен бетерү чараларында катнаша;

- авыл җирлеге территорияләрен һәм халкын табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклый, территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы буенча чаралар оештыра һәм гамәлгә куя; халыкны гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен финанс һәм материаль ресурслар белән тәэмин итүне булдыра;

- Район территориясендә урнашкан муниципаль предприятие һәм учреждениеләрнең мобилизацион әзерлеге чараларын оештыра һәм тормышка ашыра;

- авыл җирлекләре чикләрендә үз вәкаләтләреннән чыгып, халыкны гадәттән тыш хәлләрне куркынычы турында кисәтүне тәэмин итә;

- авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан су объектларында кеше тормышы һәм саулыгы куркынычсызлыгы чараларын тормышка ашыра;

- Районны ,Район чикләрен үзгәртү мәсьәләләре буенча җирле референдум, сайлау әзерләү һәм үткәрүнең оештыру һәм материаль-техник ягын тормышка ашыра;

- Район чикләрендә терроризм һәм экстремизм профилактикасында катнашу, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерә һәм (яки) бетерә;

- Район чикләрендә коррупциягә каршы тору буенча чаралар күрә;

- милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга юнәлдерелгән чараларны эшли һәм тормышка ашыра, Район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен үстерә һәм ныгыта, милли азчылык хокукларын тәэмин итүне гамәлгә ашыра, мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләү, милләтара (халыкара) низагларны булдырмау максатында профилактикалый;

8) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен үтәү өлкәсендә:

- федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

- дәүләт биргән вәкаләтләрен тормышка ашыруга каралган материаль һәм финанс чараларны тиешенчә кулланылуын тәэмин итә һәм исәбен алып бара;

- федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә дәүләт биргән вәкаләтләрне тормышка ашыру турында хисап алып бара;

- Район җирле үзидарә органнары карамагында булган материаль ресурсларның һәм финанс чараларының Район Советы карарлары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга өстәмә кулланылышын тәэ-мин итә;

9) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон һәм 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә:

- авыл җирлеге чикләрендә халыкны электр, җылылык һәм газ белән тәэмин итүне Россия Федерациясе канунчылыгы белән билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә тормышка ашыра;

- җылылык белән тәэмин итү бәя зоналарында җылылык белән тәэмин итү оешмасының төзелеш, җылылык белән тәэмин итү объектларын җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның эффектлыгын арттыру максатында реконструкцияләвен һәм (яисә) яңартуын 2010 елның 27 июлендәге «Җылылык белән тәэмин итү турында» Федераль закон биргән вәкаләтләр кысаларында муниципаль контрольдә тота;

- Россия Федерациясе законнарына ярашлы итеп (30.12.2018 үз көченә керә), торак пунктлар чикләрендә торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек (парковка урыннары булдыру һәм аларны эшләтүне тәэмин итүне дә кертеп), җирле әһәмияткә ия булган юлларның сакланышы, юл хәрәкәтен оештыру, юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү, шулай ук автомобиль юллары өлкәсендә башка вәкаләтләрне һәм юл эшчәнлеген тормышка ашыра;

- авыл җирлекләрендә яшәүче азкеремле һәм торак белән тәэмин итүгә мохтаҗ гражданнарны торак урыннар белән тәэмин итү, муниципаль торак фонды төзүне булдыру һәм аны тоту, торак төзелеш өчен шартлар булдыру, муниципаль торак контролен гамәлгә кую, шулай ук җирле үзидарәнең торак канунчылык белән бәйле башка вәкаләтләрен тормышка ашыра;

- авыл җирлекләрендә торак пунктлар арасында транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыра;

- авыл җирлекләре чикләрендә терроризм һәм экстремизм профилактикасында катнаша, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерә һәм (яки) бетерү буенча эшли;

- авыл җирлекләре чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтә һәм нәтиҗәләрен бетерә;

- авыл җирлекләрендә китапханә хезмәте күрсәтүне, китапханә фондларын комплектлау һәм саклау эшен оештыра;

- авыл җирле милкенә караган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклый, куллана һәм популярлаштыра ;

- авыл җирлекләрендә урындагы традицион иҗат үсеше өчен шартлар булдыра, авыл җирлекләрендә халык сәнгать һөнәрләрен саклау, торгызу, үстерү эшендә катнаша;

- җирлекнең генераль планын, җирдән куллану һәм төзү кагыйдәләрен раслый, территорияне планлаштыру буенча җирлекнең генераль планы нигезендә әзерләнгән документацияне раслый, төзелеш эшенә рөхсәт бирә (Россия Федерациясе Шәһәртөзү кодексында каралган очраклардан, башка законнардан кала), җирлек территорияләрендә урнашкан капиталь төзелешь объектларын эксплуатацияләүгә рөхсәт бирә, җирлек территориясен проектлауның урындагы нормативларын раслый, җирлек чикләрендәге җир кишәрлекләрен муниципаль ихтыяҗлар өчен резервка калдыру һәм алу, җирлек чикләрендә муниципаль җир контролен тормышка ашыру, хәбәрнамә нигезендә күрсәтелгән планлаштырылган индивидуаль торак яки бакча йорты төзү планлаштыруны бу кишәрлеккә куелган параметрлар нигезендә башкара, Россия Федерациясе Шәһәртөзү кодексы нигезендә корылма, зданиеләрне карау, шундый караулар барышында ачыкланган канун бозуларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр бирә, хәбәрнамә нигезендә бу

җиргә индивидуаль торак яки бакча йорты төзү ярамауны белдерә, муниципаль җирлек территориясендә төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак яки бакча йорты шәһәртөзү эшчәнлеге турында шартларга туры килү-килмәве турында хәбәрнамә бирә, Россия Федерациясе гражданлык канунчылыгы нигезендә авылара территориләрдә рөхсәтсез төзелгән корылмаларны юкка чыгару, авылара территориләрдә рөхсәтсез төзелгән корылмаларны юкка чыгару яки куелган таләпләргә яраклаштыру турында хәбәрнамәләр бирә, гамәлгә куелган җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, территорияне планлаштыру документациясен тикшерүне, җирлек территорияләрендә Россия Федерациясе канунчылыгына каршы килеп кулланылучы яки мак-сатчан кулланылмаучы җир кишәрлекләрен алу турында хәбәрнамә бирә, авылара территориләрдә рөхсәтсез төзелгән корылмаларны юкка чыгару яки куелган таләпләргә яраклаштыруны Россия Федерациясе Шәһәр төзү кодексы нигезендә гамәлгә ашыра;

- муниципаль урман контролен тормышка ашыра;

- авыл җирлеге территорияләрен һәм халкын табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклый, территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы буенча чаралар оештыра һәм гамәлгә куя;

- авыл җирлеге территорияләрендә һәләкәт-коткару хезмәтләре һәм (яисә) һәләкәт-коткару формированиеләре булдыра, аларны тәэмин итә һәм аның эшен оештыра;

- авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан су объектларында кеше тормышы һәм саулыгы куркынычсызлыгы чараларын тормышка ашыра;

- авыл җирлекләре территорияләрендә җирле әһәмияттәге дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм курортлар булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итә, шулай ук җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклanучы табигый территорияләрне куллану һәм саклауны муниципаль контрольләүне гамәлгә ашыра;

- Россия Федерациясе су канунчылыгы һәм су объектлары милекчесе вәкаләтләре чикләрендә халыкны су объектларын куллануның чикләүләре белән таныштыра;

- полиция участок уполномоченные вазыйфасын башкаручы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына бу вазыйфасы буенча хезмәт күрсәткән чорга торак урын бирә;

- коммерцияле булмаган социаль ориентлашкан оешмаларга «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» Федераль законның (12.01.1996) 31.1 һәм 31.3 статьялары нигезендә ярдәм күрсәтә;

- хезмәт күрсәтелүче административ участок полиция участок уполномоченные вазыйфасын башкаручы хезмәткәргә эш урыны өчен бүлмә бирү;

- авыл җирлекләре ихтыяҗы өчен ясалма җир участоклары булдыру эшләре тәэмин итү ,федераль закон нигезендә ясалма җир участоклары ясау эшләре буенча шартнамә төзүгә ачык аукцион үткәрә;

- авыл җирлекләре чикләрендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыра;

- авыл җирлекләре чикләрендә 2007 елның 24 июнендәге 221-ФЗ номерлы «Кадастр эшчәнлек турында» Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкаруда катнаша.

10) башка вәкаләтләр:

- муниципаль хезмәтләр реестры оештыру һәм алып бару тәртибен билгели;

- муниципаль архив эшчәнлеген тәэмин итә;

- федераль законнар нигезендә, үз вәкаләтләре чикләрендә халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләр оештыра;

- урам-юл челтәре объектларына адреслар бирә, адресларны үзгәртә һәм гамәлдән чыгара, урам-юл челтәре элементларына (федераль мәгънәгә ия автомобиль юллары, региональ һәм муниципальара автомобиль юлларыннан кала) атамалар бирә, мондый атамаларны үзгәртә һәм гамәлдән чыгара, дәүләт адрес реестрында мәгълүмат урнаштыра;

- муниципаль-шәхси партнерлык өлкәсендә Россия Федерациясе иҗтимагый партнеры буларак катнаша һәм 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы «Муниципаль-шәхси партнерлык, Россия Федерациясендә муниципаль-шәхси партнерлык һәм Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 18 статьясы 2 өлеше нигезендә каралган вәкаләтләрне тормышка ашыручы вәкаләтле орган булып тора;

- Районның җирле әһәмияткә ия булган, канунчылык, әлеге Устав, Район Советы карарлары белән Район Советы, Район Башлыгы яки Районның башка җирле үзидарә органнары компетенциясенә карамаган башка вәкаләтләрен тормышка ашыра.

2. Башкарма комитет мәсьәләләр чишү буенча Районның җирле әһәмияткә ия булмаган түбәндәге вәкаләтләрне тормышка ашыра:

- Район музейларын төзи;

- опека һәм попечителлек эшчәнлегендә катнаша;

- Район территориясендә белән бәйле җирле милли-мәдәни автономияләр хокукларын тормышка ашыру белән бәйле эшчәнлек башкаруга шартлар тудыра;

- Район территориясендә Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларга ярдәм күрсәтә;

- туризм үсеше өчен шартлар тудыра;

- кеше хокукларын тәэмин итүне җәмәгать күзәтүендә тотучы җәмәгать күзәтү комиссияләренә һәм мәҗбүри тоту урыннарында булган затларга ярдәм күрсәтә;

- 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе инвалидларын социаль яклау» Федераль закон инвалидларның җәмәгать оешмаларына ярдәм күрсәтә;

- 2012 елның 20 июлендәге 125-ФЗ номерлы «Кан һәм аның компонентлары донорлыгы» Федераль законы белән каралган чараларны тормышка ашыра;

- авылара территория торак пунктында нотариус булмаган очракта, нотариаль эшчәнлек башкара;

- федераль законнар нигезендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын федераль законнар нигезендә бәйсез бәяләү уздыруга шартлар тудыра, шулай ук оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен ведомство буйсынуындагы оешма җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә, оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын тикшергәндә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү өчен чаралар кабул итү буенча куллана;

- хокук бозуларны кисәтү өлкәсендә 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә хокук бозуларны кисәтү системасы нигезләре турында» Федераль законында каралган чараларны тормышка ашыра;

- инвалидлар һәм мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культура һәм спорт , адаптив физик культура һәм адаптив спорт белән шөгыльләнүенә ярдәм күрсәтә;

- Россия Федерациясенең 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы «Кулланучылар хокукларын саклау турында» Законында каралган кулланучылар хокукларын саклау чараларын тормышка ашыра.

3. Район Башкарма комитеты Районның җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрен чишү буенча канунчылык, әлеге Устав, Район Советы карарлары белән Район Советы, Район Башлыгы яки Районның башка җирле үзидарә органнары компетенциясенә карамаган башка вәкаләтләрен тормышка ашыра.

4. Район Башкарма комитеты муниципаль контрольне гамәлгә куярга вәкаләтле орган булып тора.

Район Башкарма комитетының муниципаль контроль өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) тиешле территориядә муниципаль контроль оештыру һәм гамәлгә кую;

2) җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә караган региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) башкару;

3) административ регламентлар эшкәртү эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контроль тормышка ашыру, Татарстан Республикасы башкарма власть органнары тарафыннан раслана торган типовой административ регламентлар нигезендә, вәкаләтләре җирле үзидарә органнарына бирелгән региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) административ регламентын тормышка ашыру. Күрсәтелгән административ регламентларны эшкәртү һәм кабул итү Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары билгеләгән тәртиптә башкарыла;

4) күрсәтелгән эшчәнлек өлкәсендә муниципаль контроль нәтиҗәлелеге мониторингы оештыру һәм үткәрү, күрсәткечләр һәм уздыру методикасы, Районның вәкаләтле җирле үзидарә органнары башкара торган муниципаль контрольдән тыш, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана;

5) федераль законнар һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән каралган вәкаләтләрне башкару.

Муниципаль контрольне турыдан-туры башкару мондый органнар-ның статусын билгеләүче хокукый актлар белән Районның Башкарма коми-теты органнарына йөкләнергә мөмкин.

2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы «Дәүләт контроле һәм муниципаль контроль башкарылганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законы нигезләмәләре муниципаль контрольне оешма тарафыннан башкару һәм юридик затларны, шәхси эшкуарларны тикшерү белән бәйле мөнәсәбәтләргә керә.

5. Районның Башкарма комитеты терроризм профилактикасында катнашу буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне чишкәндә, шулай ук ул чагылыш тапканда, нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) бетерү буенча:

1) терроризм профилактикасы, шулай ук ул чагылыш тапса, аның нәтиҗәләрен нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) бетерү буенча муниципаль программалар эшкәртә һәм гамәлгә куя;

2) муниципаль берәмлекләрдә терроризның асылын һәм иҗтимагый куркыныч булуын, шулай ук гражданнарда терроризм идеологиясенә карата тискәре караш булдыру буенча мәгълүматый- пропаганда чаралары, аңлату эшләре үткәрә, шул исәптән мәгълүматый материаллар, басма продукция тарата;

3) терроризм профилактикасы, шулай ук ул чагылыш тапса, аның нәтиҗәләрен нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) бетерү буенча федераль башкарма хакимият органнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары уздыра торган чараларда катнаша;

4) муниципаль милектә яки җирле үзидарә органнары карамагында булган объектларның антитеррористик сакланышы таләпләре үтәлешен тәэмин итә;

5) терроризм профилактикасы, шулай ук ул чагылыш тапса, аның нәтиҗәләрен нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) бетерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма власте органнарына тәкъдимнәр юллый ;

6) терроризм профилактикасы, шулай ук ул чагылыш тапса, аның нәтиҗәләрен нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) бетерү мәсьәләләре буенча җирле әһәмияткә ия башка вәкаләтләрне дә тормышка ашыра.

## 46 статья. Район Башкарма комитеты җитәкчесе

1. Район Башкарма комитетын Район Башкарма комитеты җитәкчесе җитәкли.

2. Район Башкарма комитеты җитәкчесе Район җирле үзидарә органы вазыйфаи заты булып тора.

3. Район Башкарма комитеты җитәкчесе үз вәкаләтләрен даими нигездә башкара.

4. Аерым оештыру-эш бирү функцияләрен үтәү өчен Район Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасарлары бар.

Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан очракта, я булмаса аңа карата я процессуаль суд чаралары белән сак астына алынса яки вакытлыча вазыйфасыннан алынса, вакытлыча булмаса (авыру яки чираттагы ялы аркасында) яки вәкаләтләрен үтәү мөмкинлеге булмаса, аның вәкаләтләрен билгеләнгән вазыйфалар бүленеше буенча вакытлыча Район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарларының берсе башкара.

5. Район Башкарма комитеты җитәкчесе укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш башка түләүле эшчәнлек, эшкуарлык белән белән шөгыльләнә алмый. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүе яки Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, фәкать чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый.

Район Башкарма комитеты җитәкчесе идарә органнары , попечительлек яки күзәтү советлары, башка чит ил коммерцияле булмаган органнарга , дәүләти түгел оешмаларга һәм Россия Федерациясе территориясендә эшләүче структур бүлекчәләр составына, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүе яки Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, керә алмый.

6. Район Башкарма комитеты җитәкчесе 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» федераль законы, 2012 елның 3 мартындагы 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфалары үтәүче, һәм башка затларның чыгымнары белән керемнәре туры килү контроле турында» федераль законы, 20013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе чикләреннән тыш урнашкан чит ил банкларында акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклау, счетлар ачу һәм саклау, чит ил финанс инструментлары булдыру һәм куллану турында» Федераль законы нигезендә каралган чикләүләр, тыюларны сакларга, вазыйфаларын үтәргә тиеш.

47 статья. Район Башкарма комитеты җитәкчесе билгеләү тәртибе

1. Район Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү конкурс нигезендә башкарыла.

Конкурс шартлары, аны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, контракт проекты массакүләм мәгълүмат чараларында конкурс үткәрелүдән кимендә 20 көн алдан бастырылырга тиеш.

2. Конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясе әгъзалары саны билгеләнә.

Конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысы Район Советы белән, ә калган яртысы Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер-министры) белән билгеләнә.

3. Район Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына зат Район Советы тарафыннан конкурс комиссиясе конкурс нәтиҗәләре буенча сайланган кандидатлар арасыннан куела.

4. Район Башкарма комитеты җитәкчесе өчен контракт шартларын Район Советы раслый. Федераль закон яки Татарстан Республикасы законы белән Район җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләре бирелсә, контрактка һичшиксез Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән шартлар кертелә.

5. Район Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт Район Башлыгы тарафыннан төзелә.

48 нче статья. Район Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре срогы

1. Район Башкарма комитеты җитәкчесе бу вазыйфага затны Район Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләү карарын раслаган Район Советы вәкаләтләре срогына билгеләнә һәм 5 ел тәшкил итә.

2. Район Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре срогы чыкканнан соң билгеләнгән тәртиптә яңа Район Башкарма комитеты җитәкчесе билгеләнгәнче үз вәкаләтләрен үтәүне дәвам итә .

49 статья. Район Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре

Район Башкарма комитеты җитәкчесе:

1) Район Башкарма комитеты эшчәнлеге белән шәхси идарә принциплары белән җитәкчелек итә һәм Район Башкарма комитеты тарафыннан аның компетенциясенә керә торган вәкаләтләрне үтәве өчен шәхси җавап тота;

2) Район Советы, Район Башлыгы, Районның башка җирле үзидарә органнары, башка муниципаль берәмлекләр, дүәләт власте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән белән мөнәсәбәтләрдә Район Башкарма комитетын тәкъдим итә;

3) Район Советы каравына Район бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап тәкъдим итә;

4) )Район Советы каравына Район үсешенең социаль-икътисадый стратегияләре проекты һәм аның үтәлеше турында хисап тәкъдим итә;

5) Район Советы раславына Район Башкарма комитеты структурасы проекты кертә, Район Башкарма комитеты штат расписаниесен расланган структура нигезендә, билгеләнгән хезмәткәрләр саны һәм хезмәт өчен түләү фондын да кертеп раслый;

6) Район Башлыгы белән килештереп, Район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарларын билгели һәм эштән азат, алар арасында вазыйфалар бүлә , Район Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре һәм башка эшчеләрне вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, аларның эшен контрольли, аларга карата мактау һәм җаваплылыгы чаралары күрә;

7) үз вәкаләтләре чикләрендә расланган бюджет нигезендә Район акчалары белән идарә итә;

8) Район Советы карары нигезендә муниципаль кыймматле кәгазьләр чыгару, кредитлар алу, муниципаль гарантияләр бирү юллары белән муниципаль бурыч алуларны гамәлгә куя;

9) тормышка ашыра һәм (яки) Район Башкарма комитеты Район җирле үзидарә органнарына Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкаруны тәэмин итә, аларның үтәлеше өчен шәхси җавап тота; тиешле законнар нигезендә һәм законнар үтәлеше өчен дәүләт вәкаләтләрен башкару белән бәйле хокукый актлар чыгара;

10) Район Башкарма комитеты компетенциясенә карый торган җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр, шулай ук Район Башкарма комитеты эшен оештыру мәсьәләләре буенча хокукый актлар;

11) кимендә елга бер тапкыр яки Район Башлыгы , Район Советы таләбе белән үз эшчәнлеге һәм Район Башкарма комитеты эшчәнлеге турында Район Советына хисап бирә;

12) халыкка даими рәвештә Район Башкарма комитеты эшчәнлеге турында мәгълүмат бирә, Район Башкарма комитеты эшчеләре тарафыннан гражданнар кабул итүләр оештыра, кимендә айга бер тапкыр гражданнарны шәхси кабул итә, гражданнарның тәкъдим,гариза һәм шикаятьләрен кабул итә, алар буенча карарлар чыгара;

13) Район мәнфәгатьләрен саклау һәм тәэмин итү буенча чаралар үткәрә, Район Башкарма комитеты исеменнән судка гариза бирә, ышаныч кәгазе бирә;

14) Район Советы раслау өчен Район Башкарма комитеты органнары турында нигезләмә проектлары тәкъдим итә;

15) Район Советы билгеләгән тәртип нигезендә Район Башкарма комитеты органнары җитәкчеләрен билгели һәм эштән азат итә;

16) Район Башлыгы тәкъдиме белән Районның Финанс-икътисад палатасы һәм җир мөнәсәбәтләре рәисләрен билгели һәм аларны отставкага җибәрү турында каралар кабул итә;

17) канунчылык, әлеге Устав, Район Советы карарлары һәм төзелгән контракт нигезендә башка вәкаләтләрне дә тормышка ашыра.

50 статья. Район Башкарма комитеты җитәкчесенең вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуы

1. Район Башкарма комитеты җитәкчесенең вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үлем;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) контрактны әлеге статьяның икенче яки өченче өлеше нигезендә өзү;

4) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗномерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 74 нче статьясы тәртибендә отставкага китү;

5) суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки эшкә чикләнгән сәләтле дип тану;

6) суд тарафыннан кайда булуы билгесез дип тану, яки үлгән дип игълан итү;

7) аңа карата судның гаепләү карары үз көченә керү;

8) даими яшәү урынына Россия Федерациясе чикләреннән чыгу;

9) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылу, чит ил гражданлыгы туктатылу - аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланган булырга, чит ил гражданлыгы алырга яисә аларга Россия Федерациясе гражданинының Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашмаган чит

ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документ алырга , җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклы;

10) хәрби хезмәткә чакырылу яки аны алыштыра торган альтернатив граждannар хезмәтенә җибәрелү;

11) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 13 статьясы нигезендә Районның үзгәртеп корылуы;

12) Район чикләрен үзгәрткәннән соң, сайлаучылар саны 25 проценттан күбрәккә арткан очракта;

13) Район Башкарма комитеты җитәкчесенең вәкаләтләрен үтәүченең Район Башлыгы вазыйфасына күчүе;

14) мәсьәләне гражданнарның турыдан-туры үз теләкләрен белдерү юлы белән чишүе өчен таләп ителә торган муниципаль хокукый акт чыгару срогын бозу;

15) 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» федераль законы, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым категорияләрдәге затларның аерым категорияләренә счет ачуны һәм аларны саклауны тыю турында» федераль законы белән Россия Федерациясе территориясендә урнашкан чит ил банкларында урнашкан акчалар һәм кыйммәтләрне сакларга һәм, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану» Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне үтәмәү.

2. Район Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт ике якның да теләге яки гариза нигезендәге суд карары белән түбәндәге очракларда өзелергә мөмкин:

1) контракт шартларының җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр чишүгә бәйле өлешен, шулай ук әлеге Уставның 45 статьясының 5 өлешендә каралган чикләүләрне үтәмәгәндә Район Советы яки Район Башлыгы тарафыннан;

2) Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер-министры) тарафыннан-контракт шартларының Район җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә аерым дәүләт вәкаләтләрен үтәмәүшулай ук әлеге Уставның 45 статьясының 5 өлешендә каралган чикләүләрне үтәмәгәндә;

3) Район Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан - Район җирле үзидарә органнары һәм (яки) Татарстан Республикасы дәүләт власте органнары тарафыннан контракт шартлары үтәлмәгәндә.

3. Район Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору канунчылыгы нигезендә үткәрелгән тикшерү барышында, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым категорияләрдәге

затларның аерым категорияләренә счет ачуны һәм аларны саклауны тыю турында» Федераль закон белән Россия Федерациясе территориясендә урнашкан чит ил банкларында урнашкан акчалар һәм кыйммәтләрне сакларга һәм, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану» Федераль законнары белән билгеләнгән чикләүләрне үтәмәү фактлары ачыкланса, Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер-министры) гаризасы буенча суд нигезендә өзелергә мөмкин.

## VI Бүлек. РАЙОН СОВЕТЫ, РАЙОН БАШЛЫГЫ ҺӘМ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

### Статья 51. Район Советы, Район Башлыгы һәм Район Башкарма комитеты мөнәсәбәтләре нигезләре

1. Әлеге Устав белән каоалган вәкаләтләр бүленеше нигезендә Район Советы, Район Башлыгы һәм Район Башкарма комитеты үз вәкаләтләрен мөстәкыйль башкаралар.

2. Район Советы һәм Район Башкарма комитеты канунчылык, әлеге Устав белән каралган формаларда Район халкы мәнфәгатьләрендә Районның икътисадый һәм социаль үсеше процесслары белән нәтиҗәле идарә итү юнәлешендә бер-берсенә тәэсир итәргә тиеш.

3. Район Советы һәм Район Башкарма комитеты кабул ителгән хокукый актларны имзаланганнан соң 7 көн эчендә бер-берсенә җибәрәләр.

4. Район Советы, Район Башлыгы Район Башкарма комитеты Җитәкчесенә Район Башкарма комитеты, аның башка вазыйфаи җитәкчеләре хокукый актларын кабул итү, кире кагу, үзгәртү турында мөрәҗәгать итәргә мөмкиннәр, шулай ук суд тәртибендә алар өстеннән шикаять бирергә хокуклы.

5. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе Район Советына, район Башлыгына Район Советы, Район Башлыгы хокукый актларын кабул итү, кире кагу, үзгәртү турында мөрәҗәгать итәргә мөмкин , шулай ук суд тәртибендә алар өстеннән шикаять бирергә хокуклы.

6. Район Башлыгы Район Башкарма комитеты Җитәкчесенә Район Советы эш планнарын һәм Район Советы карарлары проектларын Район Советы регламентында билгеләнгән тәртиптә юллый.

7. Район Советы, аның органнары, Район Башлыгы тарафыннан үткәрелә торган утырышларда, киңәш бирү тавышы хокукы белән Район Башкарма комитеты Җитәкчесе, аның урынбасарлары яки аларның вәкаләтле затлары катнашырга хокуклы. Район Башкарма комитеты вазый-аи затлары язмача чакыру булганда Район Советы утырышларында катнашырга бурычлы.

8. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе уздыра торган утырышларда Район Башлыгы, Район Советы депутатлары катнашырга хокуклы .

52 статья. Район җирле үзидарә органнары арасындагы бәхәсләрне чишү

Район җирле үзидарә органнары арасында аларның вәкаләтләрен тормышка ашыруга кагылышлы бәхәсләрне чишү я ризалаштыру процедуралары, я суд тәртибендә чишелә.

## VII БҮЛЕК. РАЙОННЫҢ БАШКА ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ

53 статья. Районның Контроль-хисап палатасы

1. Районның Контроль-хисап палатасы даими эшләүче муниципаль финанс контроле органы булып тора һәм Район Советы белән хасил ителә.

2. Районның Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлардан тора.

2. Районның Контроль-хисап палатасын оештыру, эшчәнлеге тәртибе, вәкаләтләре Россия Федерациясенең Бюджет кодексы, 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап орган-нарын оештыру һәм алар эшчәнлегенең гомуми принциплары турында», 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнары, Россия Федерациясенең башка федераль законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Районның Район Советы белән расланган Контроль-хисап пала-тасы турында Нигезләмәсе, башка муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнә.

Федераль законнар белән билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә булса, Районның Контроль-хисап палатасын оештыру, эшчәнлеген көйләү шулай ук Татарстан Республикасызаконнары белән дә тормышка ашырыла.

54 статья. Районның Финанс-бюджет палатасы

1. Районның Финанс-бюджет палатасы җирле үзидарә органының даими эшләүче финанс органы булып тора, түбәндәгеләрне башкара:

- Район бюджеты проектын төзи (бюджеты проектын һәм урта сроклы финанс планы);
- Район Советына раслауга кертү өчен Район бюджеты проектын кирәкле документлары һәм материаллары белән Район Башкарма комитетына тәкъдим итә (бюджеты проектын һәм урта сроклы финанс планы);
- Район бюджеты үтәлешен оештыра;
- Район бюджеты үтәлеше турында хисап төзү тәртибен билгели;
- Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм (яки) Районның алар нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен көйләүче муниципаль хокукый актлары нигезендә җирле үзидарә органының финанс органы вәкаләтләрен башкара.

2. Районның Финанс-бюджет палатасы җирле үзидарә органының финанс органы вәкаләтләрен тормышка ашырганда Район Башкарма комитетына хисап тота.

3. Районның Финанс-бюджет палатасы үз эшчәнлеген канунчылык, әлеге Устав һәм Районның Район Советы белән расланган Финанс-бюджет палатасы турында Нигезләмәсе нигезендә тормышка ашыра.

Районның Финанс-бюджет палатасы Рәисе Район Башлыгы тәкъдиме белән Район Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан куела. Районның Финанс-бюджет палатасы Рәисе Россия Федерациясе Хөкүмәте башкарма власте вәкаләтле федераль органы билгеләгән квалификацион шартларга җавап бирүче затлар арасыннан сайлап алына.

4. Районның Финанс-бюджет палатасы Рәисе Районның җирле үзидарә органы вазыйфаи заты булып тора, Район финанс органы эшчәнлеге белән җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра .

5. Районның Финанс-бюджет палатасы Район гербы сурәтләнгән һәм үз атамасы язылган мөхер, бланкларга ия.

6. Районның Финанс-бюджет палатасы эшчәнлеген тәэмин итүче чыгымнар Район бюджетында Россия Федерациясе бюджеты чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән күрсәтелә .

55 статья. Районның мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы

1. Районның мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җирле үзидарә органының даими эшләүче финанс органы булып тора һәм үз вәкаләтләре чикләрендә муниципаль мөлкәт, шул исәптән Район милкендә булган җирләр, хуҗалык җәмгыятьләре капиталындагы акцияләр, өлешләр (вкладлар) белән идарә итә.

Районның мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Районның муниципаль мөлкәт реестрын Россия Федерациясе Хөкүмәте башкарма власте вәкаләтле федераль органы билгеләгән тәртиптә алып бара.

Районның мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы вәкаләтләрен тормышка ашырганда Район Башкарма комитетына хисап тота.

2. Районның мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы үз эшчәнлеген канунчылык, әлеге Устав һәм Районның Район Советы белән расланган Районның мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турындагы Нигезләмәсе нигезендә тормышка ашыра.

3. Районның мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Район Башлыгы тәкъдиме белән Район Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан куела.

4. Районның мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе җирле үзидарә органы вазыйфаи заты булып тора, мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре идарәсе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра.

5. Районның мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Район гербы сурәтләнгән һәм үз атамасы язылган мөхер, бланкларга ия.

6. Районның мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы эшчәнлеген тәэмин итүче чыгымнар Район бюджетында Россия Федерациясе бюджеты чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән күрсәтелә .

## VIII бүлек. САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

### 56 статья. Районның сайлау комиссиясе

1. Районның сайлау комиссиясе муниципаль сайлаулар, җирле референдум Район Советы депутатын, Район Башлыгын чакыртып алу буенча, Район чикләрен үзгәртү, Районны үзгәртү буенча тавыш бирүгә әзерлек һәм аны үткәрүне оештыра.

2. Районның сайлау комиссиясе җирле үзидарә органнары структурасына керми торган муниципаль орган.

3. Районның сайлау комиссиясе Район Советы тарафыннан 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу хокукы төп гарантияләре һәм сайлау хокуклары» Федераль закон һәм Татарстан Республикасының Сайлау Кодексы белән билгеләнгән тәртиптә формалаштырыла.

Районның сайлау комиссиясе кандидатлар исемлеге тәкъдим итүче, Россия Федерациясе Федераль Җыелышы Дәүләт Думасында, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатлары бүленешенә кертелгән сәяси партияләр; кандидатлар исемлеге тәкъдим итүче, Татарстан Республикасының Сайлау Кодексы нигезендә депутат мандатлары бирелгән сәяси партияләр; кандидатлар исемлеге тәкъдим итүче, Район Советында депутат мандатлары бүленешенә кертелгән сайлау берләшмәләре; сайлаучыларның яшәү, эшләү, хезмәт, уку урынындагы җыелышлары; Районның сайлау комиссиясенең элекке составы; Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә формалаштырыла.

4. Район Советы сайлау комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан яртысын түбәндәге тәкъдимнәрдән чыгып билгеләнә:

1) кандидатлар исемлеге тәкъдим итүче, Россия Федерациясе Федераль Җыелышы Дәүләт Думасында депутат мандатлары бүленешенә кертелгән сәяси партияләр тәкъдиме ;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатлары бүленешенә кертелгән сәяси партияләр, шулай ук Татарстан Республикасының Сайлау Кодексы нигезендә депутат мандатлары бирелгән сәяси партияләр тәкъдиме;

3) кандидатлар исемлеге тәкъдим итүче, Район Советында депутат мандатлары бүленешенә кертелгән сайлау берләшмәләре тәкъдиме.

3. Район Советы сайлау комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан яртысын Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә билгели.

4. Районның сайлау комиссиясе вәкаләтләре срогы биш ел.

5. Районның сайлау комиссиясе тавыш бирү хокукы белән 8 әгъзадан формалаштырыла.

6. Районның сайлау комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итүче чыгымнар Район бюджетында Россия Федерациясе бюджеты чыгымнары классифи-кациясе нигезендә аерым юл белән күрсәтелә.

7. Районның сайлау комиссиясе вәкаләтләре, аның эшчәнлек тәртибе һәм гарантияләре федераль канунчылык, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав белән көйләнә. Районның сайлау комиссиясе вәкаләтләре Район Советы мөрәҗәгате нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән, территориаль сайлау комиссиясенә йөкләнә ала.

## X Бүлек. РАЙОН БАШЛЫГЫ ҺӘМ РАЙОННЫҢ БАШКА МУНИЦИПАЛЬ ВАЗИФАЛАРНЫ БАШКАРУЧЫЛАРНЫҢ СОЦИАЛЬ ҺӘМ БАШКА ГАРАНТИЯЛӘРЕ

### 60 статья. Даими нигездә эшләүче Район Башлыгы һәм аның урынбасарлары, Район Советы депутатларының, башка вазыйфаи затлар эшчәнлегенең социаль һәм башка гарантияләре

Даими нигездә эшләүче Район Башлыгы һәм аның урынбасарлары, Район Советы депутатларының, башка вазыйфаи затларга бирелә торган социаль һәм башка гарантияләр, Татарстан Республикасының 2009 елның 12 февралендәге 15-ЗРТ номерлы «Муниципаль берәмлек вәкаләтле органының депутат вәкаләтләрен гамәлгә кую, Татарстан Республикасында җирле үзидарә сайланулы вазыйфаи заты гарантияләре турында» Законы һәм Район Советы карарлары белән билгеләнә.

### 61 статья. Район Башлыгы, Район Советы депутатларының иминлек гарантияләре

1. Район Советы депутатларының, шул исәптән Район Башлыгының да хокуклары иминлек гарантияләре, аларны җинаять яки административ җаваплылыкка тартканда, тоткарлау, арест, тентү, сорау алган вакытта, аларга карата башка җинаять-процессуаль һәм административ-процессуаль эшләр үтәгәндә, шулай ук депутатларга карата, аларның торак һәм (яки) хезмәт урыны, багажы, шәхси һәм эш транспорты чаралары, хатлар язышу, алар куллана торган элемтә чаралары, аларныкы булган документларны оператив - эзләү эшләре вакыт тикшерүләр федераль законнар белән билгеләнә.

2. Федераль закон нигезендә Район Советы депутаты, сайлау вакытында үзенең Район Башлыгы статусына туры килә торган фикерен, карашын белдерүе һәм башка эшләр өчен җинаять һәм административ җаваплылыкка тартыла алмый, шулай ук аның вәкаләтләре срогы үткәннән соң да. Бу Район Советы депутаты тарафыннан гавәми мыскыл итү, яла ягу һәм башка федераль законнар белән җаваплылыкка тарту каралган гамәлләргә карамый.

## XI Бүлек. РАЙОН ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

### 62 статья. Районның җирле үзидарә органнары һәм җаваплы затларының җаваплылыгы

Районның җирле үзидарә органнары һәм җаваплы затлары Район халкы, дәүләт, физик һәм юридик затлар алдында федераль законнар нигезендә җаваплы.

### 63 статья. Район Советы депутатларының Район халкы алдында җаваплылыгы

1. Район Советы депутатларының, шул исәптән Район Башлыгының, Район халкы алдында җаваплылыгы депутатның аны сайлаган сайлаучылары ышанычын югалту нәтиҗәсендә килеп чыга.
2. Сайлаучылары ышанычын югалткан Район Советы депутаты, шул исәптән Район Башлыгы, вәкаләтле җирлек депутаты федераль канунчылык белән каралган тәртиптә һәм очракларда чакыртып алынырга мөмкин.

### 64 статья. Районның җирле үзидарә органнары һәм җаваплы затларының дәүләт каршында җаваплылыгы

Федераль закон нигезендә район Советының, Район башлыгының, Район Башкарма комитеты җитәкчесенең дәүләт алдында җаваплылыгы алар тарафыннан Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституциячел законнарны, федераль законнарны, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын һәм әлеге Уставны бозган очракта, шулай ук район җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен тиешенчә гамәлгә ашырмау очрагында тиешле суд карары нигезендә башлана.

### 65 статья. Районның җирле үзидарә органнары һәм җаваплы затларының юридик һәм физик затлар алдында җаваплылыгы

Районның җирле үзидарә органнары һәм җаваплы затларының юридик һәм физик затлар алдында җаваплылыгы федераль канунчылык белән каралган тәртиптә җитә.

66 статья. Ышанычларын югалту аркасында затларны, муниципаль вазыйфаларны эштән җибәрү (эшеннән азат итү)

1. Муниципаль вазыйфа башкаручы зат, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль норматив хокукый актлар белән каралган түбәндәге ышаныч югалту очракларында эштән җибәрү(эшеннән азат итү)гә дучар була:

1) мәнфәгатьләр конфликтын, бер ягында үзе торганда, булдырмый калу һәм (яки) көйләү буенча чаралар күрмәсә;

2) үз керемнәре, мөлкәте һәм милек характерындагы вазыйфаларын, шулай ук тормыш иптәшенең һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм милек характерындагы вазыйфаларын күрсәтмәү яки дөреслеккә туры килмәгәнчә күрсәтү;

3) федераль закон белән каралган очраклардан тыш, түләүле шартларда коммерцияле оешма идарәсендә катнашуы;

4) эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнсә;

5) Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә итү органнары, Попечительләр яки күзәтү советлары, чит илләрнең коммерцияле булмаган оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган структур бүлекчәләре составына керсә.

2. Муниципаль вазыйфа башкаручы зат, үзенә буйсынучы затның шәхси мәнфәгатьләрен кайгыртып, мәнфәгатьләр конфликты килеп чыгуын яки килеп чыгу мөмкинлеген, бер ягында үзе торганда, булдырмый калу һәм (яки) көйләү буенча чаралар күрмәсә, аңа карата ышаныч югалганга күрә, эштән җибәрә (эшеннән азат итә).

## XII Бүлек. РАЙОННЫҢ МУНИЦИПАЛЬ ХОКУКЫЙ АКТЛАРЫ

67 статья. Районның муниципаль хокукый актлар системасы

1. Районның муниципаль хокукый актлар системасына түбәндәгеләр керә:

1) Район Уставы;

2) җирле референдумда кабул ителгән хокукый актлар;

3) Район Советының норматив һәм башка хокукый актлары;

4) Район Башлыгының, Район Башкарма комитетының, башка органнар һәм җирле үзидарә вазыйфаи затларының әлеге Устав белән каралган хокукый актлары.

2. Район Уставы һәм җирле референдумда кабул ителгән, хокукый актлар итеп рәсмиләштерелгән карарлар, муниципаль хокукый актлар системасында югары юридик көчкә ия актлар Районның бар территориясендә дә кулланылалар һәм туры гамәлгә ия булып торалар .

Башка муниципаль хокукый актлар әлеге Уставка һәм җирле референдумда кабул ителгән хокукый актларга каршы килергә тиеш түгелләр.

3. Җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары белән кабул ителгән муниципаль хокукый актлар, Районның бар территориясендә дә үтәлергә тиеш.

Муниципаль хокукый актларны үтәмәгән өчен гражданнар, оешма җитәкчеләре, дәүләт власте органнары вазыйфаи затлары, җирле үзидарә органнары вазыйфаи затлары федераль и законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җавап тоталар.

4. Муниципаль хокукый актлар тиешле муниципаль хокукый актны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан, суд тарафыннан, җирле үзидарә органнары тарафыннан федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны җайга салучы өлешендә - мондый органнары яисә тиешле вазыйфалар җиңеләйтелгән йә күрсәтелгән органнар яки вазыйфаи затлар исемлегендә үзгәрешләр кертелгән очракта Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы , йә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан юкка чыгарылырга яки туктатылырга мөмкин.

5. Норматив характерга ия булмаган муниципаль хокукый актның гамәлдә булуы җирле үзидарз органы яисз җирле үзидарзнең вазыйфаи заты тарафыннан Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан тиешле күрсәтмә алынган очракта кичекмәстән туктатыла. Алынган күрсәтмәнең үтәлеше турында җирле үзидарәнең башкарма-боеру органнары яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары Россия Федерациясе Президенты каршындагы вәкаләтле вәкилгә өч көнлек срокта, ә җирле үзидарәнең вәкаләтле органнарына алар тарафыннан карарлар кабул ителгән көннән өч көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

68 статья. Гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерүләре юлы белән кабул ителгән карарлар

1. Җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү җирлектә яшәүче гражданнарның үз теләкләрен турыдан-туры белдерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Әгәр җирлек халкының турыдан-туры ихтыярын белдерү юлы белән кабул ителгән карарны тормышка ашыру өчен муниципаль хокукый актны, җирле үзидарә органы яисә күрсәтелгән актны кабул итү (бастырып чыгару)кирәк булса, җирле үзидарә органы яки Район үзидарә органының вазыйфаи заты өстәмә рәвештә кирәк булса, референдумда кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән алып 15 көн эчендә тиешле муниципаль хокукый актны әзерләү һәм (яисә) кабул итү срогын билгеләргә тиеш. Күрсәтелгән срок өч айдан артып китә алмый.

3. Гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерүләре юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципаль хокукый актны чыгару срогын бозу Район Башлыгы кире алу, Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең

вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә Район Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату өчен нигез булып тора.

69 статья. Районның җирле үзидарә органнары һәм җаваплы затлары кабул итә торган муниципаль хокукый акт төрләре

1. Районның җирле үзидарә органнары һәм җаваплы затлары үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү өчен түбәндәге муниципаль хокукый актларны кабул итәләр:

1) Район Советы - Район Советы карарларын;

2) Район Башлыгы - Район Башлыгы карарларын һәм боерыкларын;

3) Район Башкарма комитеты Җитәкчесе - Район Башкарма комитеты карарларын һәм боерыкларын.

2. Район җирле үзидарә органнарының башка җаваплы затлары әлеге Уставта, аларның статусын билгеләүче башка муниципаль хокукый актларда каралган вәкаләтләренән чыгып боерыклар һәм күрсәтмәләр чыгаралар.

70 статья. Муниципаль хокукый актларны әзерләү

1. Муниципаль хокукый актларның проектлары аларны алып бару мәсьәләләре буенча Район Башлыгы, Район Советы депутатлары, Район Башкарма комитеты Җитәкчесе, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, инициативалы гражданнар төркемнәре, шулай ук Районның Контроль - хисап палатасы, Районның Финанс-бюджет палатасы, Районның милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы тарафыннан кертелергә мөмкин.

2. Кайбыч Районы прокуроры һәм югары дәрәҗәдә торучы прокурор-лар үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Кайбыч муниципаль Районының гамәлдәге муниципаль хокукый актларын камилләштерү кирәк дип тапсалар, аларны үзгәртү, тулыландыру, бетерү турында яисә кабул итү турындагы муниципаль норматив хокукый актлары тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

3. Муниципаль хокукый актларны кертү тәртибе, аларга теркәлә торган документлар исемлеге һәм формасы Район Советы Регламенты, Район Башлыгы, Район Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.

71 статья. Район Советы хокукый актлары

1. Район Советы федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав белән аның компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Районның бар территориясендә дә үтәлергә тиешле кагыйдәләр билгели торган , Район Башлыгын отставкага җибәрү, Район Советы Регламенты һәм башка Район Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча карарлар чыгара.

2. Район Советы карарлары канунчылык, әлеге Устав белән каралган очраклардан тыш, Район Советы депутатларының билгеләнгән санының күпчелеге тавышы белән кабул ителә.

3. Җирле салымнар һәм җыюларны, Район бюджеты чаралары чыгымнарын гамәлгә ашыруны истә тота торган Совет карарлары, Район Советына карарга кертелсен өчен Район Башкарма комитеты Җитәкчесе инициативасы яки аның бәяләмәсе булырга тиеш. Күрсәтелгән бәяләмә Район Советына карар проекты Район Башкарма комитетына тәкъдим ителгәннән соң 30 көн эчендә бирелә.

Район Советы карарларын кабул иткәндә Район Башлыгы тавышы Район Советы депутаты тавышы кебек исәпләнә.

4. Район Советы карарлары Район Башлыгы тарафыннан кабул ителгәннән соң 3 көн эчендә имзалана һәм әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә халыкка чыгарыла.

72 статья. Район Башлыгы хокукый актлары

Район Башлыгы федераль законнар, Татарстан Республикасы закон-нары, әлеге Устав белән билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә Район Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча, шулай ук 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, башка федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав белән аның компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча хокукый актлар чыгара.

73 статья. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе хокукый актлары

Район Башкарма комитеты Җитәкчесе федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав, Район Советы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә, Район җирле үзидарә органнарына федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук Район Башкарма комитеты боерыклары белән Район Башкарма комитеты эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру белән бәйле җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча Башкарма комитет карарлары бастыра.

74 статья. Муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка тарату) һәм муниципаль хокукый актларның гамәлгә керү тәртибе

1. Район Советы карарлары, аның үзендә башкасы каралмаган булса, Район Башлыгы имзалаган көннән гамәлгә керә.

Район Советының салымнар һәм җыемнар турында норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә гамәлгә керә.

Район Советының  Район Уставын кабул итү яки әлеге Уставка үзгәртүләр кертә турындага карарлары федераль законда,  әлеге Уставта каралган тәртиптә гамәлгә керә.

2. Район Башлыгы, Район Башкарма комитеты Җитәкчесе, башка җирле үзидарә органы вазыйфаи затлары хокукый актлары  башкасы әлеге актларда каралмаган булса, имзаланган көннән гамәлгә керә.

3. Кеше һәм гражданин хокуклары, иреге  һәм вазыйфаларына кагылышлы, оештыручысы муниципаль берлек булган оешмаларның хокукый статусларын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар,  шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм  «Кайбыч таңнары» газетасында рәсми рәвештә бастырылганнан (халыкка игълан ителгәннән) соң гамәлгә керә.

Муниципаль  норматив  хокукый акт яки җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр тексты “Кайбыч таңнары” район газетасында чыкканнан соң рәсми бастырылган дип санала.

Муниципаль  норматив  хокукый акт яки җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләрне рәсми рәвештә бастыру (халыкка игълан итү) өчен челтәрдәге басмаларны да кулланырга мөмкин.  Муниципаль  норматив  хокукый актның тулы тексты челтәрдәге басмада чыгарылса, күләмле график һәм таблицалы кушымталар кәгазь басмада  китерелмәсә дә ярый.

3. Муниципаль норматив хокукый акт яки җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләрне, аерым өлешләрен халыкка тарату  федераль закон белән тыела торган  муниципаль  норматив  хокукый актлардан тыш, рәсми рәвештә бастыру (халыкка игълан итү) тәртибе  муниципаль берәмлек Уставы белән билгеләнә һәм  гражданнарга алар белән танышу мөмкинлеге бирергә тиеш.

4. Һәр муниципаль  норматив  хокукый актның  реквизитлары булырга тиеш: атамасы, имзалау датасы (Район Советы кабул иткән хокукый  актлар өчен – шулай ук аны Район Советы кабул иткән  датасы да), рәсмиләштерү  номеры, хокукый актны имзалаган кешенең атамасы.

5. Район  бюджеты турында, аның үтәлеше турында хисап, җирле салымнар һәм җыемнар билгеләү турында, һәм Район Советы, Район Башлыгы, Район Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән башка хокукый актлар (аерым өлешләрен халыкка тарату федераль закон белән тыела торган  муниципаль норматив  хокукый актлардан тыш),  кул куйган көннән алып җиде көн эчендә рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка хәбәр ителергә) тиеш.

6. Җирле референдум билгеләү, Район чикләрен үзгәртү, Районны үзгәртү, Район Башлыгы һәм аның урынбасарларын сайлау,  Район Башкарма комитеты Җитәкчесе һәм аның урынбасарларын билгеләү турында һәм башка норматив булмаган хокукый актлар да канунчылык нигезендә бастырылырга (халыкка таратылырга) тиеш .

7. Бастырылуы (халыкка таратылуы ) канунчылык яки әлеге Устав белән мәҗбүри булмаган норматив булмаган хокукый актлар Районның аларны чыгарган

органнар яки җирле үзидарә органнары вазыйфаи затлары тарафыннан бастырылырга (халыкка таратылырга) мөмкин.

8. Бастырып чыгарганда (халыкка игълан ителгәндә) муниципаль хокукый актның реквизитлары күрсәтелә.

9. Рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка игълан итү түбәндәге чаралар белән гамәлгә ашырыла:

- хокукый акт текстын «Кайбыч таңнары» район газетасында, я булмаса Район территориясендә таратыла торган башка басма чараларда бастыру. Башка басма чараларда бастырганда бу бастыруның рәсми булуы билгеләп үтелә;

- хокукый акт яки хокукый акт проектын Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастыру;

- хокукый акт текстын Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар урамы, 7нче йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүматый стендта.

Күрсәтелгән стендлар саны һәм аларны урнаштыру урыннары Район Советы белән раслана һәм Район халкына муниципаль хокукый акт тексты белән каршылыксыз танышу мөмкинлеге бирергә тиеш.

- хокукый акт текстын Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру (pravo.tatarstan.ru).

10. Муниципаль норматив хокукый актны бастырып чыгарганда (халыкка игълан ителгәндә), басма мәгъләмат чарасының чыгу датасы күрсәтелергә тиеш.

11. Муниципаль норматив хокукый актлар, шул исәптән хокукый актлар кебек язылган, җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән, оештыру һәм алып бару , Татарстан Республикасы законында ка-ралган тәртиптә, Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгы белән алып барыла торган карарлар, Татарстан Республикасы муниципаль нор-матив хокукый актлар регистрына кертелергә тиеш.

## XIII Бүлек. РАЙОННЫҢ ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЕ

### 75 статья. Районның икътисадый нигезе

Районның икътисадый нигезен Район муниципаль милкендә булган мөлкәт, Район бюджеты чаралары , шулай ук Районның милек хокуклары тәшкил итә.

### Статья 76. Районның муниципаль мөлкәте

1. Муниципаль берәмлекләр мөлкәтендә түбәндәгеләр булырга мөмкин :

1) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон белән җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне чишү өчен кирәк булган мөлкәт;

2) 2) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән җирле үзидарә органнарына аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен каралган мөлкәт, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 15 статьясының 4 нче бүлегендә каралган тәртиптә аларга тапшырылган җирле үзидарә органнарының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт;

3) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый актлары нигезендә җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

4) хәл итү хокукы федераль законнар белән бирелгән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәк булган мөлкәт;

5) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 17 статьясының 1 һәм 1.1 бүлекләре нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү өчен кирәк булган мөлкәт.

2. Районның Әлеге статьяның 1 бүлеге шартларына туры килми торган мөлкәткә милекче хокуклары барлыкка килсә, күрсәтелгән мөлкәт куллану максатын үзгәртүгә яки милекне алуга дучар ителә. Мондый мөлкәтне милектән алу тәртибе һәм сроклары федераль закон белән билгеләнә.

77 статья. Районның муниципаль мөлкәтенә ия булу, куллану һәм идарә итү

1. Районның җирле үзидарә органнары Район исеменнән вәкаләтләрне әлеге Устав белән каралганча чикләүне исәпкә алып, мөстәкыйль рәвештә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган Район җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль мөлкәткә ия булалар, аның белән кулланалар, идарә итәләр.

2. Район җирле үзидарә органнары муниципаль мөлкәтне физик һәм юридик затларга, Россия Федерациясе дәүләт власте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт власте органнарына һәм башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына вакытлыча яки даими файдалануга тапшырырга, федераль законнар нигезендә милектән төшерергә, башка килешүләр төзүгә хокуклы.

3. җирле үзидарә органнары муниципаль Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле федераль башкарма власть органы билгеләгән тәртиптә мөлкәт реестры алып баралар.

78 статья. Муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр һәм хуҗалык җәмгыятьләре

1. Әлеге Устав белән билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә Район муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләрне булдырырга, үзгәртеп корырга һәм бетерергә, хуҗалык җәмгыятьләре, шул исәптән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципальара җәмгыятьләр төзүдә катнашырга хокуклы. Муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләргә карата оештыручының функцияләрен һәм вәкаләтләрен вәкаләтле җирле үзидарә органнары гамәлгә ашыра.

2. оештыручы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы вәкаләтле җирле үзидарә органнары муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләрнең максатларын, бурычларын һәм эшчәнлек тәртибен билгелиләр, аларның уставларын раслыйлар, әлеге предприятиеләр һәм учреждениеләрнең җитәкчеләрен билгелиләр һәм аларны җитәкчелектән азат итәләр, әлеге Устав һәм муниципаль хокукый актлар белән каралган тәртиптә аларның эшчәнлекләре турында хисапны тыңлыйлар.

3. Районның җирле үзидарә органнары муниципаль казна учреждениеләре йөкләмәләре буенча субсидиар җитәкчелек белән җавап бирәләр һәм Россия Федерациясе Гражданнар кодексы белән билгеләнгән тәртиптә аларның үтәлешен тәэмин итәләр.

79 статья. Район җирле үзидарә органнарының муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләре

Район җирле үзидарә органнарының муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар, шулай ук физик затлар белән мөнәсәбәтләре башкасы канунчылык белән билгеләнмәгән булса, шартнамә нигезендә алып барыла.

## XIV Бүлек. РАЙОННЫҢ ФИНАНС НИГЕЗЕ

80 статья. Район бюджеты

1. Район үз бюджетына ия.

2. Район бюджеты Район Советы норматив хокукый акты формасында эшләнә һәм раслана.

3. Район бюджетында Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкаруга җибәрелә торган керемнәр һәм Районның җирле үзидарә органнары тарафыннан үзләренә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен бирелгән субвенцияләр,

шулай ук күрсәтелгән керемнәр һәм Район бюджетының тиешле чыгымнары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган субвенцияләр аерым карала.

4. Җирле үзидарә органнары федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең федераль органнарына һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына Район бюджеты үтәлеше турындагы хисапларны тапшыралар.

81 статья. Районда Бюджет процессы

1. Район бюджеты проектын төзү һәм карау, Район бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен тикшереп тору, Район бюджеты үтәлеше турындагы хисапны төзү һәм раслау Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләрне үтәү белән Район җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашырыла.

2. Район Советының Район бюджетын раслау турында карары, аның үтәлеше турында еллык хисап, Район бюджеты үтәлеше турында квартал саен белешмәләр, җирле үзидарә органнарының, муниципаль учреждение хезмәткәрләренең саны турында, факттагы чыгымнарны күрсәтеп, аларны «Кайбыч таңнары» район газетасында яки Кайбыч муниципаль районының «Интернет» информацион-телекоммуникацион челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

3. Җирле салымнар турында хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында Район Советының муниципаль норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәрен үзгәртүгә китерә торган, чираттагы финанс елында һәм план чорында үз көченә керә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлары Чираттагы финанс елына һәм план чорына Район бюджеты турында карар Чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет турындагы проект Район Советына кертелгәннән соң 10 көннән дә калмыйча кабул ителергә тиеш.

4. Районда бюджеты Проекты 3ел срокка төзелә һәм раслана (чираттагы финанс елы һәм план чоры ).

5. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Район бюджеты турындагы проект Районның чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итү максатында Районның социаль-икътисади үсешен фаразлау нигезендә төзелә.

6. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Район бюджеты проекты Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, әлеге Устав нигезендә кабул ителгән Район җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда төзелә.

7. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Район бюджеты проекты төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

- Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә карата таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Җыелышына юлламасы нигезләмәләре;

- Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы;

- айон бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре һәм Районның салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

- Районның социаль-икътисади үсеш фаразы;

- озак срокка бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразы үзгәрешләре проекты);

- муниципаль программалар (муниципаль программа проектлары, муниципаль программа үзгәрешләре проектлары).

8. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Район бюджеты турындагы карарда бюджет керемнәренең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты, шулай ук Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль хокукый актлары нигезендә кабул ителгән башка күрсәткечләрдән торган төп характеристикалар булырга тиеш.

9. Район бюджеты турындагы карарда , әгәр алар Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнмәгән булса, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль хокукый актлары нигезендә кабул ителгән җирлек бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативлары булырга тиеш.

10. Район бюджеты турында карар белән түбәндәгеләр билгеләнә:

- Район бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеге;

- Район бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге;

- чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы законы, Район Советының муниципаль хокукый акты белән билгеләнгән чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (төркемнәре һәм төркемчәләре), максатчан статьялары (муниципаль программалар һѐм эшчәнлекнең максатчан булмаган юнѐлешләре), төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре), бюджетлар чыгымнары төрләре төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре), төркемнәре (төркемчәләре) һәм төркемчәләре) буенча, шулай ук бюджетлар чыгымнары төрләре;

- чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет чыгымнарының ведомство структурасы;

- гавәми норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме;

-чираттагы финанс елында һәм план чорында башка Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар күләме;

- план чорының беренче елына Район бюджеты чыгымнарының шартлы рәвештә раслано торган (расланган) чыгымнарының гомуми күләме гомумин бюджет чыгымнарының гомуми күләменнән 2,5 проценттан да ким булмаган (бюджетның Россия Федерациясе бюджет системасының максатчан билгеләнеше булган башка бюджетлардан алынган бюджетара трансфертлар чыгымнарыннан

тыш ) күләмдә, план чорының икенче елына гомуми бюджет чыгымнарының гомуми күләменнән 5 процenttan да ким булмаган күләмдә;

- чираттагы финанс елына бюджет дефицитын финанслау чыганаклары;

- чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычның иң югары чиге, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның иң югары чиге күрсәтелгән югары чиге;

- Район бюджетының Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Район Советы муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән башка күрсәткечләре.

11. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Район бюджете турында карар проекты план чорына расланган бюджет параметрларын үзгәртү һәм аларга план чорының икенче елы параметрларын өстәү юлы белән раслана.

Чираттагы финанс елына һәм план чорына Район бюджете турында карар Проекты план чорының расланган бюджет күрсәткечләрен тәгаенли һәм план чорының икенче елына төзелә торган бюджет күрсәткечләрен раслый.

12. Бюджет турындагы карар проекты белән бер үк вакытта Район Советына түбәндәгеләр дә тәкъдим ителә:

- чираттагы финанс елыннан һәм план чорына Район бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

- Районның узган агымдагы финанслау елының якынча социаль-икътисадый үсеш нәтиҗәләре һәм узган чорга Районның көтелгән социаль-икътисадый үсеш нәтиҗәләре;

- Район чираттагы финанс елына һәм план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразлары;

- чираттагы финанс елына һәм план чорына Район берләштерелгән бюджетының (бюджет керемнәренең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты) төп характеристикалары фаразы;

- Район бюджеты проектына аңлатма язуы;

- бюджетара трансфертлар методикалары (методикалар проектлары) һәм аларны бүлүне исәпләү;

- чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычның иң югары чиге;

- чираттагы финанс елының үтәлеше фаразларын бәяләү;

- әгәр дә Районның Финанс-бюджет палатасы белән күрсәтелгән бюджет сметалары арасында аңлашылмаучанлыклар килеп чыкса, күрсәтелгән органнарның Район Советы, Районның Контроль-исәп палатасы белән тәкъдим ителгән бюджет сметалары проектлары;

- Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм әлеге Устав белән билгеләнгән башка документлар һәм материаллар.

13. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Район бюджете Проекты төзү Районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы, федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан

Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

14. Район Башкарма комитеты Район Советына чираттагы финанс елына һәм план чорына Район бюджете турында карар Проектын агымдагы елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча кертә.

15. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Район бюджеты һәм аны раслау турындагы карар проектын карау тәртибе (Район Советы муниципаль норматив хокукый акты белән билгеләнә) Чираттагы финанс елының 1 гыйнварыннан бюджет турындагы карар үз көченҽә керүен, шулай ук күрсәтелгән карар нигезендә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 184.1 статьясы нигезендә күрсәткечләрне һәм характеристикаларны раслауны күздә тотарга тиеш.

16. Россия Федерациясе Бюджет кодексы яисә Район бюджеты турында карар белән башкасы каралмаган булса, Район бюджете турында карар 1 гыйнвардан үз көченә керә һәм финанс елының 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

Район бюджете турында карар билгеләнгән тәртиптә имзаланганнан соң 10 көн эчендә рәсми бастырылырга тиеш.

17. Район җирле үзидарә органнары Район бюджетының балансланган булуын һәм бюджет белән бәйле хокукый мөнәсәбәтләрнең федераль канунчылык һәм Татарстан Республикасы канунчылыгы нигезендә, бюджет процессын, дефицит күләмен, муниципаль бурыч структурасы һәм күләмен, Районның исполнения бюджет вазыйфаларын үтәвен көйли.

18. Район бюджеты керемнәре Россия Федерациясе бюджет канунчылыгы, салымнар һәм җыемнар турында канунчылык һәм башка мәҗбүри түләүләр турындагы канунчылык белән формалаша.

19. Район бюджеты чыгымнары Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган формаларда гамәлгә ашырыла.

20. Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән очраклардан тыш, дәүләт власте федераль органнары вәкаләтләрен, Татарстан Республикасы дәүләт власте органнарын финанслаучы Район бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашырырга ярамый.

21. Муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.

22. Районның һәр инвестицион проект буенча бюджет чыгымнарының ведомство структурасы составына кертелгән, капиталь кертемнәр программаларына кертелгән муниципаль милек капиталь төзелеш объектлары бюджет инвестицияләрен (инвестицион проект бәясе 100 мең сумнан артып китә торган) гамәлгә ашыру бюджет ассигнованиеләре .

23. Районның һәр инвестицион проект буенча бюджет чыгымнарының ведомство структурасы составына кертелгән, капиталь кертемнәр программаларына кертелгән муниципаль милек капиталь төзелеш объектлары бюджет инвестицияләрен (инвестицион проект бәясе 100 мең сумнан артып китә торган) гамәлгә ашыру бюджет ассигнованиеләре Район бюджеты җыелма бюджет исемлеге составында һәр инвестицион проект буенча аерым күренә.

82 статья. Муниципальара характердагы җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне чишү чыгымнары

1. Район составына керә торган җирлекләр, муниципальара характердагы җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне чишү өчен Район бюджеты чыгымнарына түбәндәге максатларда субсидияләр күчерәләр:

- Район чикләрендә торак пунктлар арасында федераль һәм республика күләмендә әһәмияткә ия булган юллар, күперләр, башка инженер корылмаларыннан тыш, гомуми кулланылыш юлларын, Район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән тыш күперләр һәм башка инженер корылмалары төзү һәм карап тору;

- Район чикләрендәге җирлекләр арасында халыкка һәм оешмаларга транспорт хезмәте күрсәтүгә шартлар тудыру;

- Район территориясендә яшәүчеләргә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләре территориаль программасы нигезендә, медицина ярдәме күрсәтүне оештыру (Россия Федерациясе Хакимияте тарафыннан расланган аерым территорияләрдә яшәүчеләргә башкарма властьның федераль органнарына хезмәт күрсәтүче медик-санитар хезмәте тарафыннан медицина ярдәме күрсәтелә торган территорияләр исемлегенә кергәннәрдән кала);

- көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын эшкәртү һәм утильләштерүне оештыру.

2. Күрсәтелгән бюджетара субсидияләр күләме Район Советы һәм җирлекләрнең вәкаләтле органнарының Район җирлекләре өчен бертөрле булган бер яшәүчегә, я муниципаль хезмәтләрдән кулланучыга туры килә торган норматив исәбеннән җирле бюджетлар турындагы карарлары белән билгеләнә.

3. Җирлекнең җирле үзидарә органы тарафыннан Район Советының Район бюджеты турындагы карарның Район бюджетына муниципальара субсидияләр күчерү турындагы өлеше үтәлмәсә, Районның бюджет һәм финанслар буенча департаменты Россия Федерациясе Финанслар министрлыгы билгеләгән таләпләргә туры китереп, билгеләгән тәртиптә, бюджетара субсидияләр суммасы җирле бюджетка кертелергә тиешле федераль салымнар һәм җыемнардан, махсус салым режимы, региональ һәм җирле салымнардан кергән керемнәрдән тотыла.

83 статья. Муниципальных ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар

1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендәконтракт системасы турында» Россия Федерациясе законы нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу Район бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

84 статья. Район гражданнарының үзара салым акчалары

1. Гражданнарның үзара салым акчалары дигәндә җирле әһәмияткә ия булган конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен гражданнарның бер тапкыр бирелә торган түләүләре аңлашыла. Гражданнарның үзара салымы тәртибендә түләү күләме, җирлектә яшәүчеләрнең гомуми саныннан 30 проценттан артып китә алмаган һәм алар өчен түләүләр күләме киметелергә мөмкин булган аерым категорияләрдән тыш, барлык халык өчен дә тигез билгеләнә.

2. Әлеге статьяның 1нче өлешендә каралган гражданнарның бер тапкыр бирелә торган түләүләрне гамәлгә кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда хәл ителә, ә 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законның 25.1 статьясының 1нче өлеше 4 һәм 4.1 бүлекләре нигезендә - гражданнар җыенында.

85 статья. Районның муниципаль алынмалары (муниципаль бурычы)

1. Район бюджеты кытлыгын финанслау һәм бурыч йөкләмәләрен каплау максатларында муниципаль алынмаларны гамәлгә ашырырга хокуклы.

Муниципаль алынмалар дигәндә эчке базарда Россия Федерациясе валютасында урнаштырылучы Район исеменнән кыйммәтле кәгазьләр чыгару юлы белән гамәлгә ашырыла торган муниципаль заемнар һәм җирле бюджетка Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан һәм муниципаль бурыч йөкләмәләре барлыкка килә торган кредит оешмаларыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләре нигезендә җәлеп ителә торган кредитлар аңлашыла.

2. Район исеменнән муниципаль алынмаларны гамәлгә ашыру хокукы Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Районның Башкарма комитетына карый.

3. Агымдагы финанс елы башына Район бюджетының Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән башка акчалары агымдагы финанс елында Россия Федерациясе субъекты исеменнән төзелгән товарларны кайтаруга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән дәүләт контрактларын түләүгә, әлеге дәүләт контрактлары шартлары нигезендә хисап финанс елында түләнергә тиешле хезмәтләрне, Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан җирле бюджетларга субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар бирүгә бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелергә мөмкин, аларны хисап елында бирү җирле бюджет акчаларын алучыларның акчалата йөкләмәләре өчен кирәкле сумма чикләрендә башкарылган, финанс белән тәэмин итү чыганагы күрсәтелгән бюджетара трансфертлар булган, хисап финанс елында бирелгән юридик затларга субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре күрсәтелгән субсидияләр алучыларның финанс белән тәэмин итү чыганагы күрсәтелгән субсидияләр булган акчаларын алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә күрсәтелгән максатларга файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре

суммасыннан артмаган күләмдә, Россия Федерациясе субъекты законында Россия Федерациясе субъекты бюджеты турында каралган очракларда.

86 статья. Район җирле бюджеты үтәлеше

1. Район җирле бюджеты үтәлеше Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Район бюджеты касса һәм чыгымнар бердәмлеге нигезендә үтәлә.

3. Район бюджеты үтәлешенең касса тәэмин ителеше, Район бюджеты чаралары кулланучыларның лицевой счет ачулары һәм алып барулары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы канунчылыгы билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Район бюджеты үтәлеше росписи Районның агымдагы җыелма бюджет аңлатмасы һәм Район касса планы нигезендә оештырыла.

87 статья. Бюджет хисаплылыгы. Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисап

1. Район бюджеты хисаплылыгы еллык булып тора.

2. Район бюджет хисаплылыгын Районның Финанс-бюджет палатасы бюджет чараларының тиешле баш администраторларының җыелма бюджет хисаплылыгы нигезендә төзелә һәм Районның Башкарма комитетына тапшырыла.

3. Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисап Район Советы карары белән расланырга тиеш.

4. Район бюджеты үтәлеше турындагы еллык отчетны Район Советына тәкъдим ителгәнче тышкы тикшерү узарга тиеш, ул бюджет акчалары баш администраторларының бюджет хисаплылыгын тышкы тикшерүне һәм Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләүне үз эченә ала.

Район бюджеты үтелеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү Районның Контроль-исәп палатасы тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы таләпләрен үтәп, әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә башкарыла. Район составына керүче җирлекнең вәкаләтле органы мөрәҗәгате белән, җирлеге бюджеты үтелешен тикшерү Районның Контроль-исәп палатасы тарафыннан башкарылырга мөмкин.

5. Район Башкарма комитеты аңа бәяләмә әзерләү өчен агымдагы финанс елының 1 апреленнән дә соңга калмыйча Район бюджетының үтәлеше турында хисап тапшыра. Район бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапка бәяләмә әзерләү, бюджет акчалары баш администраторларының еллык бюджет хисабын тышкы тикшерү мәгълүматларына нигезләнеп, 1 айдан артык булмаган вакытта башкарыла.

6. Район Башкарма комитеты ел саен агымдагы финанс елының 1 маеннан да соңга калмыйча отчет финанс елы өчен Район Советы карары проектын, Район

бюджетының үтәлеше турындагы башка бюджет хисаплылыгын һәм Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган башка документларны Район Советына тапшыра.

7. Район бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны карау нәтиҗәләре буенча Район Советы Район бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны раслау яисә кире кагу турында карар кабул итә.

Район Советы тарафыннан Район бюджеты үтелеше турындагы еллык хисап кире кагылган очракта, ул дөрес булмаган яки тулы чагылдырылмаган мәгълүматларны бетерү һәм 1 айдан артык булмаган сроктан кабат тапшыру өчен кире кайтарыла.

8. Район бюджеты үтәлеше турындагы карар белән хисап финанс елына Район бюджеты үтәлеше турындагы хисап Район бюджеты керемнәренең, чыгымнарының һәм дефицитының гомуми суммасы күрсәтелә. Хисап финанс елы өчен Район Советының бюджет үтәлеше турындагы карарына аерым кушымталар белән түбәндәге күрсәткечләр раслана:

- бюджет керемнәре классификациясе кодлары буенча Район бюджеты керемнәре;

- Район бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча чыгымнары;

- бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча Район бюджеты чыгымнары;

- бюджетлар дефицитын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча Район бюджеты дефицитын финанслау чыганаклары.

Район бюджеты үтәлеше турындагы карар белән шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның нигезендә төзелгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Район бюджеты үтәлешен тәэмин итүче Җирлек Советы муниципаль хокукый акты белән билгеләнгән башка күрсәткечләр дә раслана.

88 статья. Муниципаль финанс контроле

1. Муниципаль финанс контроле бюджет мөнәсәбәтләрен көйләүче Россия Федерациясе бюджет канунчылыгы һәм башка норматив хокукый актларны үтәүне тәэмин итүне тикшерү максатында тормышка ашырыла.

Муниципаль финанс контроле эчке һәм тышкы, алдан һәм киләсе контрольгә бүленә .

2. Бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә тышкы муниципаль финанс контроле Кайбыч муниципаль Районы Контроль-исәп палатасының контроль эшчәнлеге булып тора .

3. Бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә эчке муниципаль финанс контроле Кайбыч муниципаль Районы Финанс-бюджет палатасының контроль эшчәнлеге булып тора.

4. Алдан тикшерү Район бюджетын башкарганда бюджет бозуларны кисәтү һәм аларга чик кую максатында башкарыла.

5. Киләсе контроль Район бюджетын үтәү нәтиҗәләре буенча аның үтәлешенең законлылыгын, хисапны һәм исәпкә алуның дөреслеген билгеләү максатында башкарыла.

## XV Бүлек. РАЙОН УСТАВЫН КАБУЛ ИТҮ. ӘЛЕГЕ УСТАВКА ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ

### 89 статья. Район Уставы проектын әзерләү, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү тәртибе

1. 1. Район Уставы проекты, Район Советының әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы карары проекты Район башлыгы, Район Советы депутатлары, Район Башкарма комитеты җитәкчесе, Кайбыч муниципаль районы прокуроры, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре тарафыннан кертелә ала.

2. Район Уставы проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проектын әзерләү өчен Район Советы карары белән махсус комиссия төзелергә мөмкин. Күрсәтелгән комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белгечләре, экспертлар чакырылырга мөмкин.

3. Район Уставы проекты, Район Советы карары проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проекты аларны карау көненә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча «Кайбыч таңнары» район газетасында яисә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән Район Советы тарафыннан күрсәтелгән Устав проекты буенча тәкъдимнәрне бастырып чыгару (халыкка җиткерү), күрсәтелгән Устав проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, Районның күрсәтелгән карары проектында, шулай ук гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) белән бер үк вакытта оештырылырга тиеш. Район Уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук Район Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында үтәү рәвешендә үзгәрешләр кертелгәндә гражданнарның әлеге фикер алышуда катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.

4. Район Уставы проекты буенча, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында Район Советы карарлары Район Советы утырышында каралыр алдыннан әлеге Устав нигезендә гавами тыңлаулар уздырыла, моннан тыш, Район Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында үзгәрешләр кертелә.

Статья 90. Район Уставын кабул итү, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү тәртибе

1. Район Уставы проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проектын карау Район Советы Регламенты нигезендә кимендә ике укуда гамәлгә ашырыла.

2. Район Уставы проекты әлеге Уставка беренче укылышта үзгәрешләр кертү турында карар проекты кабул ителгәннән соң, күрсәтелгән проект Район Башлыгы тарафыннан төзәтмәләр кертү өчен хокук чыгару инициативасы хокукына ия субъектларга җибәрелә.

3. Район Уставы, Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Район Советы карары район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан өчтән ике өлешеннән күбрәге тарафыннан кабул ителә.

Район Уставын, Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар кабул иткәндә Район Башлыгының тавышы Район Советы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.

4. Район Уставын федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү әлеге закон актларында билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла Федераль законда, Татарстан Республикасы законында күрсәтелгән срок билгеләнмәгән очракта, Район Уставын федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү срогы тиешле федераль закон, Татарстан Республикасы законы үз көченә керү датасын, Татарстан Республикасы законын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проектын гавами тыңлауларда фикер алышу, аның буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу, Район Советы утырышларының чиратлылыгы, мондый муниципаль хокукый актны дәүләт теркәве һәм рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) срокларын исәпкә алып билгеләнә һәм, кагыйдә буларак, алты айдан артмаска тиеш.

91 статья. Район Уставының үз көченә керү тәртибе, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар

1. Район уставы, Район Советының әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы карары алар кабул ителгәннән соң Район Башлыгы тарафыннан муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органына дәүләт теркәвенә алу өчен канумнарда билгеләнгән тәртиптә җибәрелә.
2. Район уставы, Район Советының әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы карары дәүләт теркәве узганнан соң «Кайбыч таңнары» район газетасында рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) яисә Кайбыч муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://kaybici.tatarstan.ru веб-адрес буенча рәсми сайтында, шулай ук Россия Юстиция министрлыгының «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» порталында (http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф, челтәр басмасы сыйфатында теркәлү: 2018

елның 05мартындагы ФС77-72471 номерлы Эл) урнаштырылырга тиеш һәм рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

Җирле үзидарә органнары арасында төзелгән муниципаль хокукый актны яисә килешүне рәсми бастырып чыгару булып аның тулы текстын тиешле муниципаль берәмлектә таратыла торган вакытлы матбугат басмасында беренче бастырып чыгару санала.

Муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирле үзидарә органнары шулай ук челтәр басмасыннан файдаланырга хокуклы. Муниципаль хокукый актның тулы тексты рәсми челтәр басмасында басылып чыккан (урнаштырылган) очракта, аңа карата күләмле график һәм таблицалы кушымталар кәгазь басмада китерелмәскә мөмкин.

Район Уставына кертелгән җирле үзидарә органнарының структурасын, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлешүне үзгәртә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр (район уставын федераль законнарга туры китерү очракларыннан, шулай ук вәкаләтләр, вәкаләтләр сроклары, Район Башлыгын һәм җирле үзидарәнең башка сайланулы вазыйфаи затларын сайлау тәртибе үзгәрүдән тыш) Район Уставына күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актка имза салган Район Башлыгының вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң үз көченә керә.

4. Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр муниципаль хокукый акт белән кертелә, ул:

1) Район башлыгы кул куйган Район Советы карары;

2) Район Советы кабул иткән һәм Район Башлыгы кул куйган аерым норматив хокукый акт белән рәсмиләштерелергә мөмкин. Бу очракта әлеге хокукый актта Район Советы карарының аны кабул итү турындагы реквизитлары күрсәтелә. Мондый карарга Район Советының күчеш нигезләмәләрен яисә Район Уставына кертелә торган үзгәрешләрнең һәм өстәмәләрнең үз көченә керүе турындагы нормаларын кертү рөхсәт ителми.

5. Яңа редакциядәге Район Уставын Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт итеп күрсәтү рөхсәт ителми. Бу очракта Районның яңа Уставы кабул ителә, ә моңа кадәр гамәлдә булган Район Уставы һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актлар Районның яңа Уставы гамәлгә кергән көннән үз көчләрен югалткан дип таныла.